БИТАРАФЛЫК МОДАСЫ

Бүгенге җәмгыятьтә иң еш күренешләрнең берсе ул

> 7

АЛИНӘ САФИУЛЛИНА:

«Каян килә бу явызлык?!»

> 12

АЮДАЙ КӨЧЛЕ

Авыл атамасы халыкның холкына йогынты ясыймы?

> 15

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 12 (28785) | Җомга | 28 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

ДИПЛОМ – САНДЫКТА

Яшьләр БДИ баллы кайда җитә, шуңа карап укырга керәләр дә, соңыннан эшкә урнаша алмыйча интегеп йөриләр. Мондый фикерне еш ишетергә туры килә. Хаклык та бар, юристлар – төзелештә, укытучылар икмәк, май заводларында эшләр өчен 4–5 ел буе укымый бит. Белгечләр әйтүенчә, элеккеге һөнәр сайлау кагыйдәләре бүгенгә туры килми. Нәрсә үзгәргән соң?

> 6

Ишетми калмагыз

Түләүләр арта

Балалы гаиләләргә, инвалидлар, ветераннар һәм Россия Геройларына, эштә зыян күргәннәргә социаль түләүләр 1 февральдән 8,4 процентка арта. Бу хакта Россия Премьер-министры Михаил Мишустин белдерде. Хөкүмәт җитәкчесе әлеге категорияләргә керүче кешеләр дәүләттән ярдәмгә аеруча мохтаҗ дип искәртте. Йөкле хатын-кызларга бер тапкыр түләү һәм бала карау буенча айлык пособие күләмнәре дә үсә. Беренче балага ана капиталы – 524 мең сумга, икенче һәм аннан соңгы балаларга 693 мең сумга җитәчәк.

Өлкәннәрне укыталар

Татарстан Министрлар Кабинеты кабат эшли башларга ниятләүче пенсионерларны яңа һөнәргә өйрәтүне (квалификациясен күтәрү) оештыру турында нигезләмә раслаган. Аның нигезендә, өлкәннәр яшәү урыны буенча мәшгульлек үзәге биргән юллама белән укырга җибәрелә. Шул ук вакытта алар мәшгульлек үзәгендә теркәлгән булырга тиеш. Пенсионерлар ихтыяҗ зур булган һөнәрләргә, шулай ук эш бирүчеләрнең буш эш урыннары буенча кирәкле һөнәрләргә өйрәтелечәк. Алар көндез, шулай ук читтән торып-көндез белем алачак. Башка шәһәргә белемнәрен чарлауга җибәрелүчеләргә юл, яшәү чыгымнарын каплау күздә тотыла.

Татарстанда һәр дүртенче кеше – пенсия яшендә. Уртача пенсия күләме – 15475 сум.

Җылыта

Синоптиклар Татарстанда янә җылы көннәр вәгъдә итә. Шимбә – 29 гыйнварда республикада бераз гына кар явып үтәчәк. Көндез һава температурасы −6...−12 градус чикләрендә тирбәләчәк, төнге һәм иртәнге сәгатьләрдә −11...−18 градуска кадәр суытачак. Якшәмбе көнне – Татарстанда янә кар. Көндез −1...−6, төнлә −9...−4 градус. Гидрометеоүзәкнең башлангыч фаразларына караганда, киләсе атна башында урыны белән кар-буран, көчле җил көтелә. Көндез −3...+1 градуска кадәр җылытачак, төнлә термометрның терекөмеш баганасы −3...−8 градуска төшәчәк.

Беркемне дә аямый

КОРОНАВИРУС БЕЛӘН АВЫРУЧЫ БАЛАЛАР САНЫ АРТА

Коронавируска бәйле куркыныч саннар үсүен дәвам итә. Узган тәүлектә Татарстанда чир йоктыручылар саны буенча яңа антирекорд теркәлде. Инфекция 378 кешедә ачыкланган (моңа кадәр – 367. – Ред.). 50 кешене хастаханәгә салганнар, калганнары өйдә дәвалана.

Балалар арасында авыручылар саны аеруча борчуга сала. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республиканың сәламәтлек саклау министрына балаларга планлы медицина ярдәмен күрсәтүне тәэмин итү мәсьәләсен аерым контрольгә алырга кушты. Эпидемиологик вазгыятьнең катлаулы булуына карамастан, балаларга тулы күләмдә ярдәм күрсәтелергә тиеш. Вазгыять хакында Президентка көн саен хәбәр итеп торачаклар. Сүз уңаеннан, Татарстан Фән һәм мәгариф министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада 4 мәктәптә уку тулысынча туктатылган. Әлеге уку йортлары Минзәлә, Лаеш (ике мәктәп) һәм Зәй районнарында урнашкан.

Мәгълүм булганча, бу атнада балаларга коронавируска каршы вакцина ясый башладылар. Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков әйтүенчә, хәзергә 37 балага прививка кадаганнар. «Аларның хәлләре канәгатьләнерлек, вакцинацияне тыныч кичерәләр», – диде ул.

Балалардан тыш халыкның башка категорияләренә вакцина ясау эше дәвам иттерелә. Татарстанда коронавируска каршы 2378027 кеше вакцина ясаткан. Шуларның 1884142се прививканың икенче дозасын алган. Кабат вакцина ясатучылар саны – 179654.

Шул ук вакытта Россия буенча да чир таралуына бәйле шаккатарлык саннарны күзәтергә мөмкин. Бу юлы тәүлегенә 88816 кешедә коронавирус ачыкланганнар. Авыручылар арасында балалар да бар.

Вице-премьер Татьяна Голикова сүзләренчә, соңгы ике көндә чир йоктырып, хастаханәгә ятарга дучар булган балалар 36,5 процентка арткан.

– Бу хәлгә аерым игътибар бирәбез. Әлбәттә, бик борчый торган вазгыять, – дип белдерде ул Россия Президентының Хөкүмәт әгъзалары белән киңәшмәсе вакытында. Вице-премьер бу җәһәттән ил төбәкләренә коронавируска каршы чикләү чараларын кертүне сорады.

Россия Хөкүмәте коронавируска каршы дарулар сатып алу өчен төбәкләргә 20 млрд сумнан артык акча бүлеп бирәчәк. Бу хакта карарны Хөкүмәт башлыгы Михаил Мишустин имзалаган. Акчаның күп өлешен Россиядә теркәлү алмаган дарулар сатып алу өчен тотачаклар. Алар хастаханәдәге сырхауларны дәвалау өчен әһәмиятле. Калган сумма төбәкләргә бүлеп биреләчәк. Татарстанга әлеге суммадан 60 млн сумнан артык күләмдә өлеш чыгачак.

СЕЗ ИҢ КИРӘК КЕШЕ ИКӘНСЕЗ

СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ УЗГАН ЕЛГА НӘТИҖӘ ЧЫГАРДЫ

Безне алыштырып була, сезне – юк. Республика сәламәтлек саклау тармагының узган елгы эшчәнлегенә нәтиҗә ясаганда, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов табибларга әнә шулай дип мөрәҗәгать итте. Коронавирус дигән зәхмәт котырган соңгы ике елда аеруча кадерле, якын кешегә әверелгән табибларны якын итеп, үз-үзләрен саклауларын сорап әйтелгән сүз бу. Коллегия утырышында чир биргән сабаклар барланды, ачы югалтулар саналды, быелга куелган яңа максат-бурычлар тәгаенләнде.

tatarstan.ru

Тагын берәү төзеләчәк

Татарстан сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков үз чыгышында сәламәтлек саклау тармагының соңгы ике елда бөтен мөмкинлекләрне эшкә җигеп эшләвен искәртте. Чир аеруча котырган, авыручылар саны берөзлексез артып торган иң катлаулы чорда да ковид госпитальләрендә ятак урыннарга, ИВЛ аппараты, кадрларга кытлык булмавын да билгеләп үтте ул.

Бер ел эчендә республикада үлем-китем очраклары 11,5 процентка арткан. Бу – Идел буе төбәкләре арасында иң түбән күрсәткеч. «Хезмәт яшендәгеләр арасында иң күп үлем-китем очраклары Яңа Чишмә (100 мең кешегә – 862,4 очрак), Югары Ослан (821,1), Минзәлә (794,0), Сарман (791,7) һәм Кайбыч (736,5) районнарында теркәлде», – дип ачыклык кертте министр.

Республикада үлем-китем очракларына китергән иң төп сәбәп булып элеккечә үк кан әйләнеше авырулары кала бирә. Узган ел Чирмешән, Буа, Мөслим районнарында бу төркемгә кергән чирләрдән үлүчеләр саны республика күләмендәге уртача күрсәткечтән дә артып киткән. Көндәлек тормышта телдән төшмәгән коронавирус һәм ул китереп чыгарган авырулар республика халкын кырган чирләрнең «кара исемлеге»ндә – икенче урында. Беренче өлкәне яман шеш дигән афәт йомгаклый.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та республикада үлем-китем очраклары артуга борчылуын белдерде. «Россия күләмендә алганда, бездә хәлләр яхшырак. Әмма шулай да планлы медицина ярдәме, профилактика эше җитәрлек дәрәҗәдә оештырылмый дип уйлыйм. Нәтиҗәсен күреп торабыз», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ни кызганыч, узган ел Татарстанда йөкле хатыннар арасында да үлем очраклары арткан. Республикада теркәлгән 8 үлем очрагының җидесенә һаман да шул ковид сәбәпче булган. «Бүген Казанга яңа перинаталь үзәк кирәк. Куркыныч янаган йөкле хатын-кызлар, югары технологияле ярдәмгә мохтаҗ булган җитлекмичә туган сабыйлар саны ел саен арта. ЭКО мәсьәләсе дә кискен тора. Республика клиник хастаханәсендәге перинаталь үзәк кенә җитми», – дип сөйләде министр. Татарстан Президенты бу мәсьәләнең хәл ителәсен әйтте. «Казанда перинаталь үзәк төзү буенча карар кабул ителде», – диде ул.

Алдан аяк киенәсе

Узган ел Татарстанда яман шештән үлүчеләр саны 6 процентка кимегән. Әмма тынычланырга иртәрәк. «Россиянең баш онкологы Андрей Каприн, планлы профилактика эше, диспансеризация туктатылып тору сәбәпле, яман шештән үлүчеләр саны да артырга мөмкин дип фаразлый. Шуңа күрә инде хәзердән үк тиешле чаралар күрергә кирәк», – диде Марат Садыйков. Министр Республика клиник онкология диспансерының баш табибына беренчел звено эшен җитди контрольгә алырга, үлем-китем очраклары күп булган районнарга белгечләр җибәрергә кушты.

Белгечләр халыкның ниләрдән канәгать булмавын да ачыклаган. Бүген республика халкы табибларга онлайн рәвештә язылa алмау, «ашыгыч ярдәм» хезмәтен чакыртып булмаудан зарлана. Бу хакта «Диалог» коммерцияле булмаган автоном оешмасы башлыгының беренче урынбасары Ленар Фәйзетдинов хәбәр итте. Татарстан халкы медицина хезмәткәрләренең дорфа сөйләшүе, авыруларга карата битарафлык күрсәтүләре белән дә еш очрашырга туры килүен әйткән. «Бу тикшерену нәтиҗәләре медицина оешмаларында табиб белән авыруларның үзара аралашуында кытыршылыклар барлыгын күрсәтте. Белгечләр авыруларга хезмәттәшләренә караган кебек мөнәсәбәттә булырга тиеш», – диде Ленар Фәйзетдинов.

Белгечләр димәктән, бу мәсьәләгә үз чыгышында Рөстәм Миңнеханов та тукталды. «Соңгы елларда без шактый авыр, югары технологияле җиһазлар алдык. Аларда бик оста белгечләр генә эшли ала. Без төзи, сатып ала алабыз, әмма иң элек Казаннан читтә дә эшләргә әзер булган белгечләрне табарга кирәк. Республика һәм муниципаль хакимиятнең төп бурычы бу. Беренчел звено оешмаларын белгечләр белән тәэмин итмичә берни үзгәрмәячәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент коронавируска каршы вакцина ясатуның мәкерле чиргә каршы иң нәтиҗәле корал икәнлеген дә искәртте. «Омикрон» штаммы таралган шартларда бигрәк тә. Рөстәм Миңнеханов коллегиягә кадәр Казан шәһәре хастаханәләренә машина ачкычы тапшырганда да иң элек әнә шуңа игътибар итте. «Катлаулы чорда яшибез. Коронавирусның «омикрон» штаммы вазгыятьне тагын да катлауландырды. Беренчел звенога авырлык бигрәк тә артты. Безгә оператив һәм тиз булырга кирәк. Шуңа күрә Казан хастаханәләренә 88 машина тапшырырга булдык», – диде Президент.

Хәзерге вакытта Татарстанда 2,3 миллионнан артык кеше ковидка каршы прививка кадаткан. Узган ел республикада 175 вакцинация пункты хезмәт күрсәткән. Шуларның 79ы күчмә формада эшләгән. «Безне алыштырып була, сезне – юк. Президентның Премьер-министры бар, ә табиблар – алдынгы сафта эшләүче кешеләр. Бу – бик мөһим. Шуңа күрә үз-үзегезне саклагыз», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Казанда 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе базасында Президент катнашында дәвалау-реабилитация үзәге ачылды. Бирегә үзәк нерв системасы зарарлану, соматик авырулар, периферик нерв системасы, сөяк-мускул системасы авырулары, шулай ук COVID – 19 кичергән кешеләрне тернәкләндерү курслары үткәрү планлаштырыла.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

МОДА ӨЧЕН ТҮГЕЛ

Цифрлаштыруның үзгәрешләрен һәркем тоярга тиеш. Хөкүмәт йортында узган Министрлар Кабинеты һәм Татарстанның Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы коллегиясенең уртак утырышында шул максатлар яңгырады.

Россиянең цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры Мәкъсүт Шадаев Татарстанның күп кенә тармакларда, шул исәптән цифрлаштыру, заманча технологияләрне тормыш-көнкүрешкә кертү өлкәсендә дә алдынгылар рәтендә торуын билгеләп үтте. Республикада башлангыч алган күп кенә тәҗрибәләрнең (әйтик, электрон документлар әйләнеше, электрон сәүдә) соңрак ил күләмендә дә кулланылганын искәртте федераль министр.

Хәзерге тормышны интернетсыз күз алдына китерү дә кыен. Мәкъсүт Шадаев искәрткәнчә, ил күләмендә моңа бәйле зур эш алып барыла. Татарстанда мәктәп һәм фельдшер-акушерлык пунктларын интернетка тоташтыру эше тәгәлләнгән. Хәзер инде белем йортларын вай-файлы итү максаты тора. Бу җәһәттән федераль министрлык барлык укытучыларны Россиядә уйлап табылган операцион система (ОС) нигезендә эшли торган мобиль планшетлар белән тәэмин итү проектын башлап җибәрә. Республиканы да шушы проектка җәлеп итәргә җыеналар. Моннан тыш дәүләт хезмәтләрен электрон рәвешкә күчерү эше дә бара. Татарстанга бу юнәлештә дә тиңнәр юк.

Хәзер Татарстан яңа проект өчен сынау төбәк булырга җыена. Ул социаль казначылык һәм электрон паспортлар кертүгә бәйле. Министр әйтүенчә, паспортларның электрон рәвештәгесен бу ел азагына кадәр бирә башлаячаклар.

Цифрлаштыру елы кысасында, бу юнәлештә гамәлгә ашырыласы проектлар өчен Татарстан бюджетыннан 1,6 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Йорт хуҗалыкларын, салаларны интернетлы итү, мобиль интернет булмаган җирлекләрне кимету, 5G элемтәсен киңәйтү кебек күләмле эшләр турында бара сүз. Ел азагына кадәр 253 дәүләт хезмәтен электрон рәвешкә күчерү максаты куелган. Халыкның цифрлаштыруга бәйле белемнәрен арттыру да ярап куяр иде. Бу җәһәттән төрле конкурс-форум, укытулар, югары уку йортларында цифрлы кафедралар ачу нияте бар.

Айрат Хәйруллин әйткәнчә, былтыр IT-тармакка бәйле 17 меңләп җинаять теркәлгән. Шуларның 9 меңе дистанцион мошенниклык төренә карый. Ягъни банк исәп-хисап счетларыннан акча урлау, мәгълүмати һөҗүмнәр һәм башкасы. Бу мәсьәлә турында аерым сөйләшергә кирәк, дип саный министр.

Татарстан әле үзен сынап карамаган өлкә дә бар. Ул да булса – криптовалюта базары.

– Үзәк банк хаклы рәвештә моңа каршы чыга. Шул ук вакытта, кайбер мәгълүматлар буенча, Россия халкының криптовалюта белән алыш-биреш күләме елына 5 млрд долларга җитүне күрәбез, – дип аңлатты Айрат Хәйруллин. – Үзәк банк һәм Россия Хөкүмәте белән килештереп, федераль законнар кысасында, Казанны бу юнәлештә сынау төбәге буларак карарга тәкъдим итәм. Контроль булганда бу юнәлеш үзен нибек күрсәтер – шуны тикшереп карарга кирәк.

Министрның хыялында шәһәр эчендә «цифрлы квартал» төзү дә тора. Хәер, ул инде чынга ашып та килә. Тиздән «Спартак» фабрикасы урынында яңа IT-парк ачылачак. Аның республиканың мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге йөзек кашы буласына шиге юк тармак җитәкчесенең. 43 мең кв. метрга исәпләнгән мәйданда 4 меңләп яңа эш урыны булачак. Димәк, хәзерге IT-паркка караганда күбрәк компанияләрне җәлеп итәргә мөмкинлек туачак. Аны ел азагына ачарга ниятлиләр.

Бу җәһәттән Айрат Хәйруллин Мәкъсүт Шадаевка мөрәҗәгать итте. Ул республикада чит ил IT-белгечләрен резидент итеп күрергә теләп. Гражданлык бирмичә генә, аларга Татарстанда читтән торып эшләргә, банкта исәп-хисап счетлары ачарга һәм салым түләргә мөмкинлек биреп булмасмы? Министр сүзләренчә, 1,2 меңләп белгечкә кытлык бар.

«Цифрлаштыру елының әһәмияте нидә?» дигән сорау туа икән, аңа Президентның сүзләре белән җавап бирү дөрес булыр. Бу – мода артыннан куу түгел.

– Барлык өлкәләрне дә цифрлаштыру безнең эшебезнең өстенлекле юнәлеше булып тора. Шуңа күрә дә 2022 елны Цифрлаштыру елы дип игълан иттек. Иң мөһиме – уңай үзгәрешләрне кешеләр дә тойсын, – диде ул.

Айрат Хәйруллинга «акыллы квартал»ны ел азагына ачу теләген дә үзгәртергә туры киләчәк. Татарстан җитәкчесе аны Республика көненә өлгертергә кушты. «Колхозы булды, колхозчыларын җибәрегез. Белгечләрне әзерләгез», – диде ул, уенын-чынын бергә кушып.

Тулырак vatantat.ru сайтында

Алдагы елдан яхшырак

Узган елда Татарстан нефть-химия комплексының төп предприятиеләре җитештерүне 6,8 процентка арттырган.

«Татнефтехиминвест-холдинг» акционерлык җәмгыятенең Директорлар советы утырышында компания генераль директоры Рафинат Яруллин шулай дип белдерде. Утырыш Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов рәислегендә узды.

2021 елда нефть химиясе предприятиеләре республика тупланма бюджетына чама белән 87 миллиард сум (алдагы елдагыга караганда 61 процентка күбрәк) керткән. «Татнефть»нең керемнәре һәм табышы 2020 елдагы белән чагыштырганда үскән. Түбән Кама «Нефтехим» һәм Казан «Оргсинтез» – табышка салымны, «ТАИФ-НК» милеккә салымны зур күләмдә түләүгә ирешкән.

Ачык төстәге нефть продуктлары, юу средстволары һәм пластмасса әйберләр җитештерү күләме арткан. Химия һәм резина продукциясен җитештерү күләме арта. Нефть чыгару күләме дә, ОПЕК+ чикләүләренең берникадәр йомшаруы нәтиҗәсендә, узган елдагыга караганда берникадәр арткан.

2021 елда дөньяда, ихтыяҗ арту сәбәпле, энергетика ресурслары кыйммәтләнгән. Чимал, энергия һәм логистика чыгымнары үсү беренче яртыеллыкта пластиклар кыйммәтләнүгә китергән. Икенче яртыеллыкта минераль ашламалар хакы 2 тапкырдан күбрәккә арткан.

Узга елда чимал җитештерүчеләр бәя үсүдән нык откан. Нәтиҗәдә Түбән Кама «Нефтехим», Казан «Оргсинтез» һәм «Аммоний» иң зур табыш алган. «ТАИФ-НК» да, 2021 ел йомгаклары буенча, ниһаять, табышка эшли башлаган.

Партия юлы

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин кабат «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре итеп сайланды. Төбәк бүлегенең Казанда узган XXXIV конференциясе делегатлары шундый карар кабул итте. Төбәк бүлегенең узган 5 елдагы эшенә нәтиҗә ясалган җыелышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Федерация Советы Рәисенең беренче урынбасары, партиянең Генераль советы Секретаре Андрей Турчак катнашты.

Нәтиҗәләр турында сөйләгәндә, Фәрит Мөхәммәтшин узган ел Дәүләт Думасына сайлауда Татарстанның «Бердәм Россия»гә күпчелек тавыш биргәнлеген искә төшерде. Аның әйтүенчә, сайлаудагы уңышлары теләсә кайсы партиянең оештыру-сәяси мөмкинлекләрен бик ачык күрсәтә. «Бу җәһәттән горурланырлыгыбыз бар: «Бердәм Россия»гә һәм аның кандидатларына күрсәтелгән ышаныч республикада һәрвакыт югары», – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Аның фикеренчә, ирешелгән уңышларның нигезен хакимият белән җәмгыять, партия институтлары арасында урнашкан ышанычлы мөнәсәбәтләр билгели.

Гыйнвар ае башына төбәк бүлеге 45 җирле һәм 2 меңнән артыграк башлангыч бүлекне берләштерә. Аның сафларында 129 мең кеше исәпләнелә. Фәрит Мөхәммәтшин партиянең Казан, Чаллы, Алабуга, Апас, Нурлат, Яшел Үзән, Мамадыш, Югары Ослан, Кайбыч, Кукмара, Әтнә җирле бүлекләренең эшен уңай телгә алды. Аның сүзләренә караганда, партия әгъзалары төбәктәге иҗтимагый оешмалар белән актив хезмәттәшлек итеп килә.

tatarstan.ru

Пандемия шартларында партия эшендә цифрлаштыру һәм югары технологияләр аеруча әһәмиятлегә әйләнде, диде Фәрит Мөхәммәтшин. Узган елда «бердәмроссиялеләр»нең онлайн чаралары республикада яшәүче 260 меңнән артыграк кешене җәлеп иткән. Дәүләт Советы Рәисе билгеләп үткәнчә, кешеләр белән аралашып эшләү төбәк бүлеге эшчәнлегендә төп юнәлешләрнең берсе булып тора. Партия Рәисе Дмитрий Медведевның төбәк кабул итү бүлеген кертеп, барлыгы 52 иҗтимагый кабул итү бүлеге аша халык белән аралашу хәл ителеп килә.

Андрей Турчак, төбәк бүлеге эшен югары бәяләп, Фәрит Мөхәммәтшин кандидатурасын бүлек җитәкчесе сыйфатында яңа срокка тәкъдим итте. «Фәрит Хәйруллович өчен төбәк бүлегенә җитәкчелек итү – мактаулы вазыйфа түгел, ә бик җаваплы эш. Аның белән ул «24/7» режимында елына 365 көн шөгыльләнә», – дип мөрәҗәгать итте конференциядә катнашучыларга Андрей Турчак.

Конференциядә катнашучылар, Турчак фикере белән килешеп, Фәрит Мөхәммәтшин кандидатурасын хуплады һәм аны яшерен тавыш бирү юлы белән республика «бердәмроссиялеләр»е башлыгы итеп кабат сайлады.

Андрей Турчак әйтүенчә, республика халык тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән проектларны уңышлы тормышка ашырып килүче алдынгы төбәк булып тора. «Татарстан җитәкчелеге, Рөстәм Миңнеханов халыкның тормыш сыйфатын яхшырту буенча киң колачлы бурычлар куеп килә. «Бердәм Россия» өчен дә федераль «Халык программасы»нда билгеләнгән төп юнәлеш бу», – диде партиянең Генераль советы Секретаре.

Конференциянең рәсми йомгаклау өлешендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов чыгыш ясады. «Соңгы елларда байтак кыенлыклар булды, аларны бергәләшеп хәл иттек. Илне үстерү өчен кирәкле булган карарлар да, икътисадның үсеш темплары, кешеләрнең керемнәре киму дә, коронавирус пандемиясе дә бу», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты искә төшереп үткәнчә, 2021 елның декабрендә партия съездында дәүләт башлыгы Владимир Путин: «Сәясәтебез үзәгендә, планнарыбыз үзәгендә – нәкъ менә кеше», – дип билгеләп үткән. Ә партия Рәисе Дмитрий Медведев съездда «Халык программасы»нда билгеләнгән бурычларны тулысынча үтәүне төп максат итеп куйган. «Болар – безнең өчен өстенлекле бурычлар», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Әйтеп кенә бактым

«Марыш!»

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне йокыдан көлә-көлә уяндым һәм һич кенә дә туктап булмый. Хатын йокы аралаш кына: «Нәрсә булды инде?» – ди. «Булмады», – дип башыннан сыйпадым да кухняга чыгып киттем, онытылганчы күргән төшем турында язарга тотындым.

Имеш, без Мәчет тавында чана шуабыз икән. Мәчет урынында баштарак ике катлы мәктәп иде, без шунда укып чыктык. Чираттагы «эреләндерү»ләр вакытында мәктәп күрше авылга, колхоз үзәгенә күчте. Бүген аның нигезендә – клуб. Әмма «Мәчет тавы» дигән сүз өлкәннәр телендә яши әле. Без кечкенә чакларда, кыш көннәрендә әнә шул тау гөр килеп торды. Узыша-узыша чана шуа идек без, әле ярышлар да уздырдык. Изге Әдһәм абыйлар капка турысына кем беренче булып төшеп җитә – шул җиңүче саналды. Беребез капка төбендә кемнең ничәнче булып килгәнен кычкырып тора иде. Ә тау башында – старт сызыгы. Сызык ерактан күренеп торсын өчен, салкында шакыраеп каткан ат тизәкләрен юл аркылы тезә идек. Ә старт бирүче итеп азмы-күпме урысча белүче малай сайлана. «Азмы-күпме урысча» дигәне исә өч сүздән торды: «внимание», «марыш», «ыступ». Ни сәбәп, күбебез урысча «сөйләшергә» ояла иде. Әмма старт бирү бик мактаулы, җаваплы эш саналганга, шушы өч сүзне бик тырышып ятладык.

Төшемдә әнә шул вакыйгалар җанланды. Менә без, бер көтү бала, чаналарны күтәреп, старт сызыгына тезелгәнбез дә «винимание, марыш!» дигән команда көтеп басып торабыз, имеш. Әмма, команда бирүче, ул Кетер Габдулла малае Шамил иде бугай: «Винимание!» – дип кычкырды да туктап калды. Без тегеңә: «Марыш, марыш!» – дип пышылдыйбыз, ә ул, үзем беләм, дигән сыман өстән генә безгә карап ала. Без инде чабышкы атлар кебек алга сөрлегеп-сөрлегеп куябыз. Шулчак кемдер: «Марыш!» – дип кычкырды. Бу Шамил тавышы түгел иде, әмма кая ул турыда уйлау! Чаналарны күтәреп бераз йөгердек тә, чанага ятып, шуып та киттек. Колакка Кетер Габдулла малаеның: «Дөрес булмады, мин старт бирмәдем, иманыгызны киям!» – дигән сүзләре ишетелеп калды. Без аңа: «Кисәң киярсең инде!» – дип кычкырабыз, үзебез шырык-шырык көләбез, имеш. Менә шул иң кызык җирдә көлеп уяндым да инде.

Соңгы вакытта балачак мизгелләре төшемә еш керә һәм һәрберендә нигәдер елмаям, көләм. Кеше үзенең үткәне белән елмаеп саубуллаша, диләр. Ә минем балачак күптән еракта калды, күптән саубуллаштым мин аның белән.

Инде менә хәзер уйлап утырам, һәркем, бәлкем, нәкъ менә балачагын күбрәк сагынадыр, дим. Ул бит – күңелнең иң чиста, бер генә кер бөртеге дә кунмаган чагы. Шуңа күрә еллар узып, шактый «пычрангач», шактый гына гөнаһлар җыйгач, кеше, чистарынып булмасмы дип, балалыгына кайтадыр да әле. Иң кызыгы, без «балачагы авыр елларга туры килде» кебек сүзләрне еш ишетсәк тә, бу хакта китаплардан күп укысак та, балалык еллары гомернең иң матур чоры булып күңелдә саклана.

Безнең буын да: «Балачак авыр елларга туры килде», – дип зарлана ала. Мин, мәсәлән, сугыш тәмамланып, нибары дүрт ел узгач тудым. Шөкер, ач-ялангачлыкны сизмәдек. Беренче класска барганда миңа өр-яңа сатин чалбар тегеп киерттеләр, мәктәп формасы шул иде. Ашаганыбыз күбрәк бәрәңге булды. Тик бер генә дә зарланасы килми. Алай гына да түгел, сагынам мин балачакны. Сагынмасам, төшләргә кереп йөдәтмәс иде.

Менә үзем язам, үземнең авылга кайтып, Мәчет тавында чана шуасы, «Марыш!» дигән тавышка йөгереп китеп чанага капланасы һәм шуып китәсе, хәтта Кетер Габдулла малаеның: «Иманыгызны киям!» – дип кычкырганына хәтле ишетәсе килеп китә. Авылга кайтырмын кайтуын, тик инде Мәчет тавында чана шуучы балаларны гына күреп булмас. Чөнки юк алар бүген. Булганнарын санарга бер кулның бармаклары җитә, бәлки, артып та каладыр. Ярый әле, төшләремә кереп йөдәтерлек якты истәлекләр бар.

ШАРНЫ НИЧЕК САКЛАРГА?

Сизәсездер: Җир шарында вакыйгалар агымы көннән-көн кызулана һәм кайнарлана. Сәламәтлек саклау өлкәсендәге хәлләр, икътисад мәйданы, илләр һәм халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр торган саен хәвефлерәк төс ала. Газета хәбәрчесе бүген иртән (чәршәмбе көн) мәгълүмат кырын ачты һәм сөенечле бер генә хәбәр дә таба алмады.

pixabay.com

Менә Израильнең рәсми мәгълүмат кырыннан хәбәр: Коронавируска каршы көрәш мәгълүмат үзәге илдә йогышлы чирдән үлүчеләр саны кискен үсә дип хәбәр итә. Кичә үлүчеләр саны кырыктан ашып киткән. «Ватаным Татарстан» сайтыннан Татарстанда 4 кеше үлде дигән мәгълүмат укыдым. Фәләстыйнны оккупацияләү нәтиҗәсендә дөньяга килгән илдә нидидер акылга сыймый һәм аңлашылмый торган хәлләр бара, чөнки авыру йоктыручылар саны Россиядәгедән күпкә артык. Дүшәмбе көннең рәсми мәгълүматы 83 мең чирле дип күрсәтә. Бу – дөньякүләм рекорд, җан башына авыручылар саны ягыннан Израильгә бер ил дә тиңләшә алмый. Алар алып барган профилактика чаралары эшләми, дөресрәге, никтер кире якка эшли.

«Омикрон» бездә дә киң тарала, бәхеткә, чир артык катлауланулар китереп чыгармый бугай. Пандемиядән башка да дөнья вакыйгалары нык кыза. Биржа индекслары түбән төшә, валюталар тәгәрәшә, бәяләр утлы табада сикерәләр, дәһшәтле рәвештә кораллы көчләр һәм хәрби техника хәрәкәткә килә. Бу юллар авторының телефонына кичә генә Техаста тимер юл составларына хәрби техника төяләү төшерелгән видео килеп төште. Юлсыз җирләрдә йөрергә көйләнгән Humvee и LMTV автомобильләре төялгән составның очы-кырые күренми. Болар Көнчыгыш Европага – безнең чикләргә ашыга. Украина тимер юлларында да шул ук хәл. Россия дә үзенең Ерак Көнчыгыштагы «Искәндәр» ракета комплексларын һәм башка хәрби техниканы көнбатыш чикләргә китереп бетерде бугай инде. «Кая ашкынасыз, кешеләр, үткән гасырның канлы тегермәнендә тартылган фаҗигале миллионлаган язмышларны оныттыгызмыни?» – дип кычкырасы килә. Кремльдә: «Утны Украина үрләтә, якын көннәрдә Донбасста кан коярга җыена», – дип белдерәләр. Кичә генә Президент сүзчесе Песков әфәнде нәкъ шундый әчтәлекле чыгыш ясады. Британия басмасы «The Sun» Премьер Борис Джонсонның: «Россия, яшен тизлегендә һөҗүм итеп, Киевны юк итәргә мөмкин», – дигән кисәтүен таратты. Чәршәмбе иртәсендә Вашингтоннан Байденның Украинага таба хәрәкәт итсә, Путинга шәхси санкцияләр белән янавы турында хәбәр килеп төште. Ил җитәкчесенә персональ санкция кертү – тарихта сирәк күзәтелә торган күренеш, бигрәк тә держава лидерлары бер-берсенә карата беркайчан да алай кыланмыйлар һәм андый адымны атламыйлар. Бу инде – җеп өзелергә тора дигән сүз. Россия Президенты сүзчесе Песков CNNга биргән әңгәмәсендә: «Бу – безнең акыл чикләренән чыгып китә торган нәрсә», – диде.

Акылга сыйми торган хәлләр Җир шарында тагын да булып ята әле. Кичә Урта Азиядә ут бетте. Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан караңгылыкка чумдылар. Ташкентта метро эшләмәде, светофорлар сүнеп, өч илдә дә урам хәрәкәтенең буталчыгы килеп чыкты. «Күңел тыныч түгел. Мондый хәлнең беркайчан да булганы юк иде», – дип яздылар уртаазияле дуслар социаль челтәрләрдә. Имештер, Казахстанда биткоин майнерлары утны күп тотып, энергетика системасына көч китергәннәр һәм түнтәргәннәр икән.

Россия патриотлары: «Европада туңалар, Россия газ торбасының кранын кысканнан соң газ җитешми», – дип сөенешәләр. АКШ дипломатлары һәм сәясәтчеләре сугыш килеп чыккан очракта Катар газын Европага китерү турында сөйләшүләр алып баралар, Дохага басым ясыйлар. Беләсезме, газ кайда күп? Кытайда. Компартия, зур сугышка әзерләнеп, бөтендөнья икмәгенең яртысыннан артыграгын амбарларга, «зәңгәр ягулык»ны саклагычларга җыеп куйды. Хәзер чин алыпсатар компанияләре Көнбатышка газ сатарга җыеналар. Фронтның бер сызыгы Кытай белән Тайвань арасыннан узарга ихтимал иде. Коммунистлар бу ихтималлыкка җитди әзерләнгәннәр.

Дәһшәтле һәм хәвефле хәлләр чылбырын сүтүдән туктап: «Ә болар нигә кирәк соң?» – дигән сорауга җавап биреп карыйк. Алдан ук әйтеп куйыйк: акыллы һәм аңлаешлы җавап табып булмый ул сорауга. Сугышка бернинди дә мохтаҗлык юк. Бары тик дөньякүләм олигархик капитал ияләренең зур сәясәтчеләрне һәм сугыш карчыгаларын эшкә җигеп, дөнья малын яңабаштан үз файдаларына бүләргә тырышулары гына бар. Иң аянычы шунда: кемнәрнеңдер шәхси комсызлыгы, тәкәбберлеге Җир шарын куркыныч астына куя. Барыбызны да зур һәлакәт алдына китереп бастыра. «Шарны ничек сакларга?» дигән сорау кабыргасы белән килеп баса. Ул бит безнең барыбыз өчен дә берәү генә, бердәнбер.

Бу уңайдан Азиядәге бер илнең элекке Премьер-министры, Малайзия икътисади могҗизасын мәйданга чыгарган һәм шул сәбәпле дөньякүләм популярлык яулаган Мөхәммәт Махатхир үткәргән бер социаль тәҗрибә нәтиҗәләре белән уртаклашасы килә. Инде туксан җиденче яше белән баручы бу шәхес (бер-ике көн элек кенә «Фейсбук»та аның үлеме хакында хәбәр күргән идем, әмма рәсми раслау таба алмадым) башта Мәгариф министрлыгы белән җитәкчелек итә, башка тармаклар белән идарә итү тәҗрибәсен дә уза. Аннан соң 1981 елдан 2003 елга кадәр Премьер-министр булып тора. 2018 елда тагын бер тапкыр хөкүмәтне җитәкләде әле ул. 2020 елда үз теләге белән дилбегәне башка кешегә тапшырды. Менә шул шәхес 1974 елда уку елы тәмамланганда, мәктәпләр ябылу тантанасына чакырыла. Менә шунда ул укытучыларга шарлар тарата, аларны кабартып, аякларына бәйләргә куша һәм бер минут вакыт эчендә шары шартламыйча сакланып калучыларга призлар җыелмасы булуын әйтә. Андый уенны беләсездер инде? Кешеләр нишлиләр? Алар психологиясенең гаҗәп бер сыйфаты ачыла шунда: һәркем үз тирәсендәгеләрнең шарын шартлатырга тырыша. Минут үткәч, илнең булачак лидеры әйтә: «Мин сезгә башкаларның шарын шартлатырга кушмадым. Әгәр дә башкаларга карата тискәре карар кабул итмичә, тик кенә торсагыз, һәркайсыгыз приз алачак иде. Әмма тискәре фикер өстен чыкты», – ди. Әйе, без күп вакытта үз уңышыбызны башкалар уңышын җимерү хисабына гына була ала дип уйлыйбыз. Менә шул психология лидерлар аңына да сеңгән. Башкалар корганны җимерү хисабына гына үзеңнекен төзеп була дигән ялгыш фикер хакимлек итә. Ә бит лидерлар аягына бер генә шар – Җир шары бәйләнгән һәм үзең исән калу максаты белән аны шартлатырга тырышу – мәгънәсезлек.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ҖИР КАДЕРЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Җир – иң зур байлыкларыбызның берсе. Тик ни өчендер Татарстанда файдаланмый торган авыл хуҗалыгы җирләре арта. Моның сәбәпләре нидә? Җирләрне максатчан файдаланмау нәрсәгә китерә? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауларга җавап эзләде.

Кадерсезләү

Соңгы берничә көндә бу тема игътибар үзәгендә дисәк, бер дә ялгышу булмастыр. Проблема берничә министрлыкның еллык коллегиясендә дә, Министрлар Кабинетында узган киңәшмәләрдә дә кузгатылды. Четерекле мәсьәләгә карата Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та үз сүзен җиткерде һәм контрольне көчәйтергә кушты.

– Җиргә мондый мөнәсәбәттә булырга ярамый, безнең иң зур байлыгыбыз ул. Өләшеп тә караганнар… Дөрес файдаланылса, бер хәл. Авыл хуҗалыгы җирен башта сатып алалар, аннан башка категориягә күчереп куялар да сатып җибәрәләр. Авыл хуҗалыгы җирләре эшләргә тиеш, – диде ул Росреестр һәм Кадастр палатасының Татарстан буенча идарәсенең еллык коллегиясе утырышында, районнарда җирләргә контроль җитмәүгә ишарәләп. – Җир бит ул! Мәсьәләне контрольгә алырга кирәк. Теркәлгән җирләр файдаланмый икән, димәк, иң катгый чаралар күрү сорала.

Хәер, җиргә булган мөнәсәбәт саннарда да күренә. Росреестр китергән мәгълүматлар буенча, Татарстанда 4 млн 600 мең гектардан артык авыл хуҗалыгы җирләре бар. Шул ук вакытта Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсе тәкъдим иткән статистика буенча, узган ел республикада 113 мең гектар кулланылмый торган җир булу ачыкланган. Бүгенгә аларның 45 мең гектары эшкәртелә башлаган.

Файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы җирләренең күпчелеге Казан яки зур шәһәрләр тирәсендәге районнарга туры килә. Мәсәлән, беренче бишлеккә Югары Ослан (15844 гектар), Алабуга (13215 гектар), Лаеш (9345 гектар), Мамадыш (8752 гектар) һәм Әлмәт (8645 гектар) районнары кергән.

– Россия законнары буенча, авыл хуҗалыгы җирләре беренче чиратта авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен тотылырга тиеш. Аларда ашлык яки печән үстерелә, көтү көтелә. Ә эшкәртелмәгән яки тиешле максатларда кулланылмаган җирләрне без файдаланмый торган җирләр, дибез, – дип ачыклык кертте Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсенең җир күзәтчелеге буенча бүлек мөдире урынбасары Илдар Хәлилов. – Хәзерге вакытта мондый җирләрнең күпчелегендә чүп үләннәр үсә. Соңгы елларда хәтта кыргый агачлар белән капланганнары да очрый.

Белгеч әйтүенчә, җирләрне тиешенчә файдаланмау аңа бик зур зыян сала.

– Җирләрне тиешенчә файдаланмау, ташландык сөрүлекләр чәчүлек мәйданнары азаюга һәм, нәтиҗәдә, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү кимүгә китерә. Сөрүлек җирләрне бер сезон кулланмау да җиргә зур зыян сала. Алар бик тиз арада чүп үлән, агач-куаклар белән каплана һәм туфракның уңдырышлылыгын киметә. Аны кабаттан эшкәртә башлар өчен матди һәм техник чыгымнар күбрәк кирәк булачак. Туфракны эшкәрткәндә күпчелек чүп үләннәр тизрәк орлыклана һәм участокны ыгрык чүпли. Ә инде агач-куакларның тамырларын тартып чыгарганда, туфракның иң уңдырышлы өске катламына зыян килә, – ди Илдар Хәлилов.

	2020 ел	2021 ел
Файдаланылмаган җирләр	107493, 2 га	113209,2 га
Шуларның әйләнешкә кергәне	36155,1 га	45450,9 га

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәгълүматлары.

Сәбәпләре

Ташландык җирләр үзеннән-үзе барлыкка килми бит. Алар ни сәбәпле арта? Белгеч беренче сәбәп итеп, авыл хуҗалыгы җирләре дип сатып алып, башка максатларда куллану очракларын күрсәтә. Ягъни физик яки юридик зат аны авыл хуҗалыгы җире дип рәсмиләштерә дә бизнеста куллана яки корылма төзи. Җирне сатып алып, эшкәртмәүчеләр дә күп. Андыйлар гадәттә җирнең бер категориядән икенчегә күчүен көтә икән.

Файдаланылмый торган җирләре күп булган районнар исемлегендә Питрәч тә бар. Тикшерү вакытында биредә 6585 гектар җирнең эшкәртелмәве ачыкланган. Район хакимиятенең матбугат үзәге җиткергән мәгълүматларга караганда, кулланылышта булмаган җирләрнең күпчелеге (49 проценты) элеккеге «Татфондбанк»ка карый. Закон бозучылар арасында шулай ук «Простор Инвест» идарәче компаниясе дә, «Дар Группа» җәмгыяте дә, банкротлыкка чыккан «Газовик» оешмасы да, физик затлар да бар.

– Физик затларга 26 тикшерү акты төзелде, 65 мең сум штраф салынды. Бүгенгә җирләрнең 1797 гектары әйләнешкә кертелде, – диделәр матбугат үзәгендә.

Татарстанның Хисап палатасы аудиторы Александр Якупов сүзләре буенча, тикшерү вакытында авыл хуҗалыгы җирләрендә төрле объектлар (хезмәт күрсәтү өлкәсендә, сәүдә, асфальт заводы) төзелгәнлеге дә ачыклана.

– Шул ук вакытта мондый җирләрдә файдалы казылмалар чыгару буенча карьерлар ясау очраклары да күп. Гәрчә аларга рөхсәт булмаса да, – ди ул.

Мәсәлән, Азнакай районында шәхси кулларда булган авыл хуҗалыгы җирләренең берничә участогында вак таш чыгарулары билгеле булган. Шул ук вакытта җир участогының кадастр бәясе авыл хуҗалыгы өчен файдалану кебек билгеләнгән. Участокның тиешле категориягә күчерелмәве аркасында район бюджеты җир салымы буенча гына да елына 1 млн сум тирәсе акча югалткан.

– Җир участокларын файдалану буенча җирле үзидарәләргә дә шелтә бар, – ди Александр Якупов. – Мәсәлән, Балтач районында авыл хуҗалыгы участогын арендага алып тору буенча дүрт килешү төзелгән. Ләкин алар чынлыкта сәнәгать максатларында файдаланылган – бетон эшләнмәләр җитештерелгән. Бу очракта шулай ук район бюджетына акча керми калган.

Җитәкче шулай ук Актаныш районында булган хәл турында да искәртеп узды. Монда авыл халкының кирәк-ярагы өчен ком чыгара торган урынны авыл хуҗалыгы җирләре буларак рәсмиләштергән булганнар.

– Бу участокны сәнәгать җире статусына күчерергә кирәкми. Ләкин шул ук вакытта карьерның уртача тирәнлеге 10–15 метр булу ачыкланган. Ә закон буенча ул биш метрдан артып китмәскә тиеш. Моннан тыш, аның мәйданы да Экология министрлыгы билгеләгәннән артып киткән, – ди ул.

Дәүләт Думасының Аграр мәсьәләләр буенча комитет рәисе урынбасары Владимир Плотников фикеренчә, 1990 еллардагы җир реформасыннан соң файдаланылмый торган җирләр арта гына бара. Ул вакытта күп кишәрлекләр арзан бәядән үзләштерелде, ди ул.

– Нәтиҗәдә алар яки эшкәртелми, яки бөтенләй башка максатларда кулланыла. Шуңа күрә аларны әйләнешкә кертү өчен катгый чаралар күрергә кирәк, – ди депутат. – Файдаланылмый торган җирләргә берничә тапкыр зуррак салым түләтергә кирәк. Шулай иткәндә, җир хуҗасы аны сатарга, яки эшкәртергә мәҗбүр булачак. Мондый җирләрне кимету ягын очракларын да азайтыр иде. Чүп үләнне бик әйбәт яна. Җиргә ашлык чәчелсә, мондый проблема булмас иде.

Җаваплылык

Билгеле булганча, әгәр моңа кадәр авыл хуҗалыгы җирләренең максатчан файдаланылмавын исбатлау һәм әйләнешкә кертеп җибәрү өчен 5–6 ел таләп ителсә, хәзер бу эш тизрәк башкарыла. Узган атнада Россиянең авыл хуҗалыгы министры урынбасары Максим Увайдов Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсе коллегиясендә катнашты. Журналистлар белән аралашканда ул: «Без бөтен җирнең дә әйләнештә булырга тиешлеген аңлыйбыз», – дип белдерде.

– Шул максатлардан «Авыл хуҗалыгы җирләрен рәсмиләштерү» программасы кабул ителде. Җирне рәсмиләштерү, кадастр учетына куюга федераль акча бүлеп бирелә, чөнки безгә бөтен җирнең дә эшләве мөһим. Ә моның өчен аны рәсмиләштерергә кирәк. Быелдан әлеге программа гамәлгә керә һәм төбәкләрдән алынган гаризалар буенча без акча бүлеп бирәчәкбез. Бу программа кулланышта булмаган бөтен җирне дә хуҗалы итәргә мөмкинлек бирер, дип уйлыйм. Әле җирләргә инвесторлар җәлеп итеп, алга таба да авыл хуҗалыгы үстерү ягын кайгыртырбыз, – диде Максим Увайдов.

Министр урынбасарының фикерен Илдар Хәлилов та куәтли.

– Җирнең һәр хуҗасы аңа ышанып тапшырылган иң зур байлыкка җаваплы карасын иде, – ди ул. – Әгәр сатып алып та эшкәртә алмый икән, бу эшне башкара алырдай кешегә тапшырырга кирәк. Башкача булган очракта, җир хуҗасы административ җаваплылыкка тартыла һәм билгеле бер вакыт эчендә әлеге җитешсезлекләрне бетерергә тиеш була. Ә моны Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсе контрольдә тота. Өч ел узып та, җир максатына туры китереп кулланылмаган очракта, суд аны тартып алырга тиеш була.

Минталип МИННИХАНОВ, фермер:

Мин җирне бик олылап, Җир-ана дип дәшәм. Ул бит безне ашата, эчертә, яшәтә, күпме байлык алабыз аннан. Аның белән сөйләшеп йөрим мин. Безнеке кебек төбәктә буш, эшкәртелми торган җирләр булырга тиеш түгел. Әгәр хуҗа өч ел бер эш кыра алмый икән, аларны эшли торган, кадерен белә торган кешеләргә бирергә кирәк. Эшләргә теләге булган фермерлар җир ала алмыйча иза чигә. Байлар, торып торсын әле дип, ниндидер юллар белән сатып алалар да шул килеш яткыралар. Шуңа күрә бу мәсьәләне федераль һәм республика дәрәҗәсендә карарга кирәк. Законнар тагын да катгыйланырга тиеш. Җирне бирү генә түгел, аның киләчәген дә контрольдә тотарга кирәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ДИПЛОМ – САНДЫКТА

Илдар Мөхәммәтҗанов

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кемнәр кирәк?

Югары уку йортын сайлаганчы, чыгарылыш сыйныф укучыларына киләчәктә нинди һөнәр буенча эшләячәге турында уйланырга кирәк. Бу җиңел эш түгел. «2030 елга кадәр иң өстенлекле һөнәрләрне фаразлаган «Яңа һөнәрләр атласы»ннан, вузлардагы белгечлекләр, бюджет урыннары, уку бәяләре хакында «Укырга дөрес кер» сайтыннан мәгълүмат алырга мөмкин. Киләсе җиде елда югары белемгә дәүләт заказы 8 меңнән артык кешене тәшкил итә. Бигрәк тә укытучылар, табиблар, физик культура, мәгълүмати технологияләр юнәлешендәге белгечләр, инженерларга ихтыяҗ зур», – диделәр Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының югары белем бирү бүлегендә.

Бөтен яшьләрне дә бер калыпка салырга ярамый, әлбәттә. Үз һөнәрен яратып эшләүчеләр дә күп. Шул ук вакытта укытучылыктан китеп, мал асраган мөгаллимнәр дә бар. Трактор йөрткән юристлар, фермерлык эшен ачкан психологларны да очратырга мөмкин. Бер яктан, авылда эшләргә кеше бар, дип сөенергә кирәк, икенче яктан, җилгә очкан бюджет акчасы да, бушка ыштан туздырган биш ел да кызганыч.

Пешекчегә укып, кафе-рестораннарда эшләгән Рәзинә Шәрәфиева зур кәстрүлләр күтәрүдән туйган. «Эшемне яратсам да, сәламәтлек турында уйлый башладым. Көннәр буе аягүрә басып эшләгәч, аяклар аруга түзеп булмый. Май исе, пар башка каба. Дөрес, акчасы әйбәт иде. Хәзер мин – тулай торакта хуҗалык мөдире. Хезмәт хакы аз, әлбәттә. Нишләтәсең, дөньяны тигезләп бетереп булмый», – ди Рәзинә.

Кайбер яшьләр икеләнеп тә кала. Укыган һөнәр буенча тәҗрибә җитмәгәннән дә бу. Шулай ук эшләгән акча фатир арендалау өчен җитмәс дип тә борчылалар. Хезмәт хакың 20–25 мең сум булып, фатир өчен 15–20 мең түләсәң, эшләп торудан мәгънә булырмы? Автотранспорт техникумын тәмамлап, куптән түгел армиядән кайткан Фәннүр Хафизов белән дә бу мәсьәләдә гәпләшеп алдык.

– Укырга киләчәктә авылда машина төзәтү буенча үз эшемне ачармын дигән ният белән кергән идем. Әти фермер булгач, техника янында кайнашып үстем. Тик шәһәр барыбер үзенә тартты, йөргән кызым да монда. Техникумда машиналар сүтеп карау гына җитми. Студентларга практика кирәк. Эшкә дә сынап алалар хәзер. Җитәкче сорау биргәндә, аптырап калмадым. Техниканы яратуымны сөйләдем, барысын да булдыра-чакмын, дидем. Алар икеләнеп торганны яратмый. Хезмәт хакын да 50–60 мең сум кирәк, дип әйттем. Әнә бер яшь белгеч, 20 меңгә дә риза дигәч, аны бөтенләй чакырып та тормаганнар. Ялкаулар белән эш пешми. Әлегә бер атна өйрәнәм, аннан машина ремонтларга тотыначакмын, – ди автослесарь булырга җыенган егет.

Токарь, фрезеровщик – гади белгеч түгел

«Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» генераль директоры Эмиль Гобәйдуллин, замана яшьләре һөнәр сайлый белми, дигән фикер белән килешми. Соңгы елда вазгыять, киресенчә, яшьләрнең күбесенең эшче һөнәрләрен аңлы рәвештә сайлавын күрсәтә, ди. Моның сәбәбен «Ворлдскиллс» хәрәкәте, «Эшче һөнәрләр атласы», төрле проектлар булдыруда күрә.

– Элек яшьләр күбрәк әти-әнисе фикеренә игътибар итсә, хәзер үзләре теләгән белгечлеккә баралар. Алар алдан ук үзләрен сынап та карый ала. Хәзер үзмәшгуль булу, шәхси эш ачу мөмкинлеге дә бар. Шуңа күрә яшь белгечләрнең барысы да зур заводларга бармаска мөмкин. Монда оешма җитәкчеләре белән бергәләп эшләмичә булмый. Яшьләр яхшы хезмәт хакы алып, квалификациясен күтәреп, алга таба эшли алсын өчен шартлар тудыру мөһим, – дип сөйләде безгә Эмиль Гобәйдуллин. – Бүген, иртәгә генә түгел, киләчәктә актуаль булган һөнәрләрне үз теләкләре буенча сайласыннар иде. Яңа белгечлекләр барлыкка килеп тора. Хәзер токарь, фрезеровщик гади генә хезмәт түгел, ул җитештерүдән башлап, станок белән идарә итә, автоматлаштырылган технологияләрне белергә тиеш. IT, ясалма интеллект, биотехнология, биомедицина, хезмәт күрсәтү өлкәсендәге белгечләр, укытучылар, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре, эшче һөнәрләре – барысы да кирәк. Цифрлы икътисадка күчеп барсак та, кеше факторы беренче урында кала.

Эшләп карыйбызмы?

Азнакай районында яшәүче 76 яшьлек волонтер Алсу Габделхакова яшьләрне дөрес итеп һөнәр сайларга өйрәтү өчен «Эшләп карыйбыз!» дигән проект булдырган. Тик аны тормышка ашыру өчен үзәк кирәк.

– Фитнес-клубка баргач, төрле тренажерлар бар бит. Нигә әле шуларны медицина юнәлеше буенча булдырмаска? Монда сүз хастаханә турында бармый, өй шартларындагы процедураларга өйрәтүне әйтәм. Әйтик, кан басымын үлчәгәндә, йөрәк-кан тамырлары авырулары, тонометр төзелеше турында аңлатырга кирәк. Укучылар сайлыйсы һөнәре турында алдан ук белеп торсын. Кызлар мәктәптән башлангыч медицина таныклыгы белән чыгарга тиеш. Өлкәннәр лаеклы ялга китә, яшьләр медицина юнәлешенә бармаса, табиб, шәфкать туташларына кытлык булачак. Бүген бары коронавирус хакында гына сөйлиләр. Башка авыруларны күрсәтмәгәч, яшьләрнең медицина шулай булачак, дип күзаллавы бар. Эшләп карамыйча, башкаларга сөйләп булмый. Үземне дарусыз яшәргә өйрәттем. Заманында шәфкать туташы эше буенча укыттым, – ди Алсу ханым.

Өлкән яшьтәге волонтер әйтүенчә, балалар кул эшләре буенча да үзләрен сынап карый алыр иде. 5 сыйныфтан ук балаларны һөнәрләр белән таныштыру кирәк.

– Мәктәпкә баручы укучыларны туктатып: «Һөнәрләр белән алдан танышырга теләр идегезме?» – дип сораган идем, күзләрен зур итеп ачып тыңлап тордылар да берни әйтмәделәр. Технология дәресләрендә компьютерга өйрәнәләр икән. Кул хезмәте бөтен җирдә дә кирәк. Магнитлы кирпечләр ясатып, малайларны мич чыгарырга өйрәтергә мөмкин. Остазлар итеп пенсия яшендәге белгечләрне чакырырга була. Бу уен гына түгел, уены-чыны бергә булырга тиеш, – ди Алсу Габделхакова.

Сәрия МИФТАХОВА

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге:

Һөнәрне яки уку йортын дусларга яки өйгә якын булуга карап сайламыйлар. Белгечлек буенча эшкә урнашып, киләчәктә үзеңне, гаиләңне туендыру турында уйларга кирәк. Тегеяки бу белгечлек буенча хезмәт базарында ихтыяҗ булуы турында кызыксыныгыз. Элек уңышлы һөнәр сайлауда барыбызга да билгеле булган «Телим» (кызыксындырган һөнәрләр), «Булдырам» (һөнәр өчен мөһим сыйфатлар, сәламәтлек, мөмкинлекләр, тырышлык), «Кирәк» (ихтыяҗ булган һөнәрләр) дигән кагыйдә бүгенгә туры килми. Беренче булып, хезмәт базарын, кадрларга ихтыяҗ булган тармакларны, һөнәрләрне өйрәнегез. Кайсы «Кирәк», шуны ачыклагыз. Аннан шулар арасыннан үзең булдыра алырдай һәм сәламәтлегеңә туры килгәнен, (мәсәлән, балта остасы, штукатур-маляр, электр-газ белән эретеп ябыштыручы, инженер, тәзүче) «Булдырам» дигәненнең бәяли аласың. Ниһаять, шулар арасыннан күңелеңә туры килгәнне сайлап, «Телим» дигәненнең аңлыйсың. Һөнәр сайлаганчы, мәшгульлек үзәкләренә барып, нинди белгечлекләргә ихтыяҗ барлыгын, уку йортлары турында мәгълүмат алырга мөмкин.

ФИКЕР

Камил НУГАЕВ, Татарстан Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе урынбасары:

Кадрлар җитмәү проблемасы безгә генә түгел, бөтен дөньяга хас. Интернетка кереп карасаң, анда җыен түзга язмаганны күрсәтәләр. Пирамида булдыручыларны, тизрәк акча эшләп була торган белгечләрне. Анда берсе дә колхозчы турында сөйләми. Хәтта телевизорда да шулай. Элек сыер савучы, тәүче кебек хезмәт ияләрен күрсәтәләр иде. Бакчадан ук төрле уеннар аша бу һөнәрләргә мәхәббәт тудыру кирәк. БДИ дип кенә булмый. Без укыганда хезмәт дәресләрендә, егетләр – тракторчы, кызлар тегүче, ашчы таныклыгы алып чыкты. Министрлык кына түгел, теләсә кайсы фермер, компания кызыксынырга тиеш. «Кадрлар җитми», – дип кул кушырып утырудан файда юк, аларны мәктәпкә барып эзләргә кирәк. Чит илләрдә белгечләрне мәктәп, институтлардан барлыйлар, стипендияләр билгелиләр. Бездә дә элек колхоз стипендияләре бар иде. Шуларны яңадан кайтару кирәк. Предприятиеләр базасында укытуны оештыру да отышлы. Һәр һөнәргә лаеклы хезмәт хакы түләнергә тиеш. Бүген берәүнең дә канализация чокыры чистартасы килми. Көнбатышта кешене җәлеп итү өчен яхшы акча түлиләр. Компьютер, цифрлаштыру дип кенә булмый. Алары да кирәк, әмма дөнья аның белән генә барамы? Сыерны кем сава, җирне кем сукалый, урамны кем себерә? Робот шкаф астына кереп, идәнне юа алмый. 7 сыйныфта укыганда ук, агроном булам, дип карар кылган идем. Тик әтинең табиб итәсе килде. Әти-әни кушты дип кенә булмый, омтылыш кирәк. Әле ярый бармаганмын, миннән начар табиб чыккан булыр иде. Һөнәрне дөрес сайламауда баланың да, әти-әни, җәмгыятьнең дә хатасы бар. Әти-әни тәрбияләргә тиеш, ә алар тизрәк авылдан шәһәргә куып җибәрергә тели. Балаларга, бернәрсәне дә кешегә сылтамагыз, һәркем үз язмышын сайлый, дип өйрәтәм.

pixabay.com

КАЛЕБ АВЫРУЫ

БИТАРАФЛЫКНЫ НИЧЕК ДӘВАЛАРГА?

Кайсыдыр акыл иясе бу хисне куркыныч җәнлек белән чагыштырган. Берәве, дошманнан курыкма, калебен шушы хис биләп алганнардан шүрлә, чөнки ул җирдәге вәхшилек, хыянәт һәм явызлыкны тудыра торган көчләрдәндер, дигән. Сүз – битарафлык хакында. Хәзерге җәмгыятьтә ешайган күренешләрнең берсе ул. Моның сәбәпләре нәрсәдә, мәрхәмәтлелекне ничек кире кайтарырга?

Психолог, арт-терапевт Чулпан НИГЪМӘТҖАНОВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Чулпан Фидаилевна, битарафлык хисен хәзерге заман чире дип тә атарга мөмкиндер. Көннән-көн кешеләрнең каты күңеллеләнүен күзәтәбез. Ни сәбәпле шулай соң?

– Дөрестән дә, бу – безнең җәмгыять өчен шулкадәр кискен торган сорауларның берсе. Хәзер битарафлыкка мода башланды дияргә мөмкин. Нәрсә белән бәйле бу? Тамырларын кайдан эзләргә? Беренчедән, бу безнең тормышыбызга, көнкүрешебезнең тизлегенә бәйле. Замана кешесе гел каядыр ашыга. Аның туктап тын алырга, кемгәдер булышырга, тирә-юньгә карарга, башкаларның мәшәкатенә игътибар бирергә буш вакыты да юк. Үз проблемаларын хәл итә алса да рәхмәт инде, чөнки хәзер һәркем өстендә әллә ничә төрле бурычмаксат, мәшәкать. Моңа өстәп, кеше көн саен искиткеч күп күләмдә мәгълүмат белән очраша. Хәзер мәгълүмат ташкынына фильтр куеп өлгереп булмый. Җәмгыять шәхес алдына яңадан-яңа бурычлар, кагыйдәләр, калыплар китереп куя. Без исә шуларга яраргя тырышабыз, яраклашмасак, димәк, дөрес яшәмибез дип уйлыйбыз.

Җәмгыятьтә битарафлыкның киң таралуына килгәндә, иң элек, бу – элгәрәк кичерелгән рухи, хисси җәрәхәтләр фонында үзеңне яклау ысулы. Икенче сәбәп итеп башкаларның хәлен аңламау, аңлый алмау һәм аны ураклашуда катнашмауны атарга була. Ник дигәндә, кешене моңа өйрәтмәгәннәр, үрнәк күрсәтеп үстермәгәннәр. Өченче сәбәп – ярату, таяныч тоймау, кайбер очракларда, бәлки, якыннар тарафыннан кыерсытылу да. Бу сәбәпләр барысы да кешенең халәтенә көчле йогынты ясый. Әйтергә кирәк, аның орлыклары балачакта ук шыта башлый инде. Балачакта үз-үзеңне тотуның, гаилә һәм шәхес мөнәсәбәтләренең тәүге үрнәкләре формалаша. Гаилә эчендә физик яисә рухи көчләүгә дучар булганнар тора-бара башкаларның кайгысына исе китмәс була.

Психологик тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам: хәзер яшьләр арасында битарафлык күренешләре шактый күп. Үзләренә, җәмгыятькә, якыннарына карата битарафлык бу. Миңа консультацияләргә ата-аналарына үпкәләре булган яшьләр шундый күп килә башлады. Аларның сәбәпләре дә төрле. Шул үпкә мөнәсәбәтләрне боза.

:: Күп кенә шәхес үсеше тренерлары (тренеры личностного роста. – Ред.), коучлар, психологлар «үзең өчен генә яшә», «башкаларны уйлама» дип өйрәтә. Бу да үзенең йогынтысын сиздерми калмыйдыр.

– Бәгырьнең катылануы, йөрәкнең бикләнүе хәзер аеруча нык сизелә. Корънәндә дә, Библиядә дә ахырзаман якынлашкан саен кешеләр үзгәрер, аларда яхшылык бетәр, эгоистлар, рәхмәтсезләр күбәер дигән мәгънәдәге сүзләр бар. Шуны чынбарлыкта күзәтәбез дә: әйтик, кешеләр җиңел генә итеп дуслыкны өзәргә, кирәк икән, сатып та җибәрергә әзер. Беренче планга социаль абруй, акча, мал-мөлкәт чыга. Кеше шуларга табына. Психолог буларак, «үзеңне генә ярат» дигән сүзләр белән килешә алмыйм. «Башкаларга төкереп кара» дигән сүзләр кешедә эгоизм орлыклары шытарга этәргеч ясый. Шул рәвешле бүтәннәргә карата хөрмәт хисе югала.

Дуслык, кайгыртучанлык, мәрхәмәтлелекнең бәһасе кими. Минем уйлавымча, бу да – битарафлыкка этәрә торган сәбәпләрнең берсе. Үзеңне яратырга, әмма тирә-юньдәгеләрне дә онытмаска кирәк.

:: Соңгы арада бер-бер артлы куркыныч хәбәрләр өермәсендә калырга туры килде. Мисал өчен, Татарстанда, Омскида үлемгә китергән фаҗигаләр, Костромадагы 6 яшьлек кыз баланы көчләү очрагы. Кешеләрнең мондый вәхшилеген ничек аңлатырга мөмкин?

– Барлык явыз кешеләрнең дә психологик чирләре бар дип әйтеп булмый. Гадәттә, рухи авыруы булганнар барлык җинаятьчеләрнең бик аз процентын тәшкил итә. Калганнары – сәламәт кешеләр. «Тик ни өчен саусәламәт кешеләр дә явызлык юлына баса?» дигән сорау туа.

Явызлык кылу ул – безнең белән кайчандыр булган күңелсезлекләрнең, бәла-казаларның искә төшүе нәтиҗәсе дә. Алар җыела, туплана һәм кешене билгеле бер халәткә кадәр җиткерә. Бу халәттә баш мие аны-моны белештерми башлый һәм агрессиягә юл ачыла. Сәбәпләре?

Беренче чиратта, стресс. Кеше йокыдан уянуга нидер ашарга тиеш, ә табында ризыгы булсын өчен, акчасы кирәк, акча булсын өчен, керемле эш кирәк. Хезмәт хакы гел генә канәгатьләндерми. Моңа өстәп башка чыгымнар бар, һәр кешедә ипотека, кредит дисеңме. Акчага бәйлелек барлыкка килүгә, ярсый башлыйбыз, негатив фикерләр, паника уяна. Моны сизәбез. Гомумән, көн саен паникада, «Иртәгәсе көнем ничек узар?», «Иртәгә фәлән нәрсә өчен түләрлек акчам булырмы?» һәм башка уйлар белән яши кеше. Стресс тәүлек дәвамында озата йөри безне. Транспортта, «бөке»дә, гаиләдә, хезмәт урынында...

Социаль челтәрләр дә утка ялкын өстәп тора. «Инстаграм»ны ачасың: барысы да нидер эшли, өлгерә, җитешә. Менә бу тизлек, өлгерү дә мода, замана теле белән әйткәндә, тренд хәзер. Моңа карап син: «Мин тормыштан артта калам», – дисең. Һәм чаба башлыйсың. Шунысы бар: бу ашыгудан канәгатьләнү хисе алабызмы соң, әллә киресенчәме?

Явызлыкның тагын бер мөһим сәбәпчесе бар: ул да булса, агрессияне чыгарырга мөмкинлек биргән чараларның кулланышта булуы. Моңа мисал – утлы коралларны сатып алу таләпләре.

:: Негатив яңалыклар, фильмнар, китаплар да начар сыйфатлар барлыкка килүгә берникадәр йогынты ясыйдыр?

– Әлбәттә, болар безнең аңда үз эзен калдыра. Андагы геройлар үз золымнарын булдыра ала икән, нишләп әле мин дә моны эшли алмыйм, дигән уй туа. Узган елгы 175 нче гимназиядәге фаҗигане алыйк. Бер-бер артлы шуңа охшаш вакыйгалар берничә урында кабатланды бит. Әлегә җәзасыз калуын да күреп торалар. Һәрхәлдә, элеккечә бар кеше алдында асмаячаклар, кулларын кисмәячәкләр. Моны күреп, кешедә курку хисе уяна иде.

Мәгълүмат кырыбызда, кызганыч, җанга җылы өсти, өмет уята торган яңалыклар бик аз. Кайсы гына мәгълүмат чарасын алма, барысында да кемдер кемнедер үтергән, көчләгән, авария булган һәм башкасы. Ә ник соң? Кешеләргә негатив мәгълүмат кызыграк тоела, аның буенча фикер алышырга, сөйләшергә һәм, иң мөһиме, хөкем итәргә була бит. Ә позитив яңалыкка ул кадәр күп реакция булмаска да мөмкин әле.

:: Мәрхәмәтлелек хисен ничек кире кайтарырга? Гомумән, начарлык күп булган җәмгыятьтә үзеңне битарафлыктан ничек сакларга?

– Әлеге сорауга җавап кыска булыр. Бу – үзеңне кулда тоту һәм юмор хисен саклау. Позитив фикерләүне мөмкин кадәр үстерергә кирәк. Әлбәттә, хәзерге җәмгыятьтәге вазгыятьне исәпкә алсак, бу бик җиңел эш түгел. Киң күңелле булып калу да, негативка бирелмәү дә кыен. Әмма бу мөмкин.

Ихтыяр көче булган кеше күп нәрсәгә ирешә. Хәйрия эшләрендә катнашкан, башкаларга бөртек кадәр генә булса да ярдәм күрсәткән кешеләр үзен начар йогынтыдан саклый. Безнең узаңыбыз (подсознание. – **Ред.**) безне ишетә бит. Ягъни, начар уйлар уйлыйбыз икән, ул начарлыкны тартып китерәчәк. Йә киресенчә. Иң мөһиме – үзебездәге матур сыйфатларны башкаларга да сеңдерү, башкаларны хөрмәт итәргә өйрәнергә, таянырлык кыйммәтләр булдырырга, кешеләр белән аралашырга кирәк. Бөтен эштә дә үрнәк күрсәтү мөһим. Гел начарлык кына күреп-ишетеп торгач, шулай булачак та. Башкача да яши алабыз, башкача да фикерләү мөмкин икәнен исбатларга кирәк. Җаваплы эш бу. Психологларга да мөрәҗәгать итәсем килә. Белгечләрдән күп нәрсә тора бит. Киләчәктә аларга эш артачак кына әле. «Үзеңне генә ярат», – дип өйрәтү дөрес түгел. Алар да кешеләргә яхшылык, мәрхәмәтлелек, матурлык, рухи кыйммәтләр юлын сайларга булышсыннар иде.

Әңгәмәдәш – Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

31 гыйнвар | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Черное озеро» 16+
00.25 «Башваткыч»12+
01.10 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
07.15, 19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.05, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское /Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Любовь Аксенова, Ирина Пегова, Виктор Сухоруков. «ЦЫПЛЕНОК ЖАРЕНЫЙ» (S) 16+
23.25 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 «Познер» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». Новые серии 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
04.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 15.25, 18.20, 22.35 Новости
06.05, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «ДЕНЬ ДРАФТА» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 «ЕДИНСТВО ГЕРОЕВ» 16+
14.50, 15.30 «ЕДИНСТВО ГЕРОЕВ-2» 16+
16.55, 18.25 «ЛУЧШИЕ ИЗ ЛУЧШИХ» 16+
19.00 «Громко» Прямой эфир
20.00 Лига Ставок. Вечер профессионального бокса. Габил Мамедов против Вячеслава Гусева. Прямая трансляция из Москвы
22.40 Тотальный футбол 12+
23.10 Футбол. Кубок Франции. 1/8 финала. ПСЖ – «Ницца». Прямая трансляция
01.15 «Оседлай свою мечту». Док. фильм 12+
02.55 Новости 0+
03.00 Биатлон. Чемпионат Европы. Трансляция из Германии 0+
05.00 «Громко» 12+

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00 Сегодня
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
10.00 Сегодня
10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 Премьера. Антон Васильев. «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.15 Сегодня
23.35 Никита Панфилов. «ПЁС» (S) 16+
03.25 «СТРОЙКА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Чужая девочка» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
16.05 «ЖЕНСКАЯ ИНТУИЦИЯ» 16+
19.00 «КОРЗИНА ДЛЯ СЧАСТЬЯ» 16+
23.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
02.00 «Порча» 16+
02.30 «Знахарка» 16+
02.55 «Верну любимого» 16+
03.20 «Тест на отцовство» 16+
05.00 «6 кадров» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «ЛАДОГА» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня. 16+
09.20, 02.10 «ЖИВЕТ ТАКОЙ ПАРЕНЬ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.50, 14.05 «ЕСТЕСТВЕННЫЙ ОТБОР» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Сталинградская битва». Док. сериал. «Начало» 16+
19.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №89» 16+
20.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Операция «Бодигард» 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.40 «ДЕНЬ КОМАНДИРА ДИВИЗИИ» 12+
01.30 «Легенды армии». Афанасий Белобородов 12+
03.55 «ЕСТЕСТВЕННЫЙ ОТБОР» 16+

1 февраль | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Оныта алмыйм...» 0+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 « Не от мира сего...» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Чёрное озеро» 16+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники» 12+
00.50 «Черное озеро» 16+
01.15 "Реквизиты былой суеты" 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
07.15, 19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40, 16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Тамчы-шоу» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.15, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское /Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ЦЫПЛЕНОК ЖАРЕНЫЙ» (S) 16+
23.25 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 К юбилею Льва Лещенко. «Все, что в жизни есть у меня» 12+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». Новые серии 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
04.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 15.25, 18.20 Новости
06.05, 19.05, 22.00, 00.10 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.35 Спец. репортаж 12+
09.25 «ЛУЧШИЕ ИЗ ЛУЧШИХ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «МатчБол»
13.35, 15.30 «АЛИ» 16+
16.55, 18.25 «ЛУЧШИЕ ИЗ ЛУЧШИХ-2» 16+
19.55 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Париматч». Мужчины. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
22.25 Мини-футбол. Чемпионат Европы. 1/4 финала. Прямая трансляция из Нидерландов
01.00 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Баскония» (Испания) – «Зенит» (Россия) 0+
02.25 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Аргентина – Колумбия. Прямая трансляция
04.30 «Голевая неделя» 0+
04.55 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Перу – Эквадор. Прямая трансляция

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00 Сегодня
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
10.00 Сегодня
10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 Премьера. «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.15 Сегодня
23.35 «ПЁС» (S) 16+
03.25 «СТРОЙКА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Розги» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «ЗАБЫТАЯ ЖЕНЩИНА» 16+
19.00 «ДВА СЕРДЦА» 16+
23.20 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР» 16+
01.20 «Понять. Простить» 16+
02.20 «Порча» 16+
02.45 «Знахарка» 16+
03.10 «Верну любимого» 16+
03.35 «Тест на отцовство» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ЕСТЕСТВЕННЫЙ ОТБОР» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 18.30 «Спец. репортаж» 16+
09.40, 01.15 «МЫ ЖИЛИ ПО СОСЕДСТВУ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.50, 14.05 «ЕСТЕСТВЕННЫЙ ОТБОР» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.50 «Сталинградская битва». Док. сериал. «Война в городе» 16+
19.40 «Легенды армии». Виктор Дубынин. Премьера! 12+
20.25 «Улика из прошлого». Премьера! 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ЖДИТЕ СВЯЗНОГО» 12+
02.25 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
03.55 «ЕСТЕСТВЕННЫЙ ОТБОР» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 31 ГЫЙНВАР – 6 ФЕВРАЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Сөеклегезгә җылы хисләрегезне күрсәтергә оялмагыз. Беләсезме, шуннан соң үзара мөнәсәбәтләр өрьяңа биеклеккә чыгып, бөтенләй башкача яши башлаячаксыз! Кучкарларның һәммәсен дә диярлек шатлыклы вакыйгаларга һәм күңелле мәшәкатьләргә бай яллар көтә.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Бу көннәрдә һич тә ашыгырга ярамый. Барысын да төптән уйлап, салмак кына эшләгез, ашыктыручыларга игътибар итмәгез. Хаталану куркынычы булса, бармакка бармак та сукмагыз. Хафаланасы юк: соңга калып эшләү тагын да яхшырак нәтиҗәләргә китерәчәк!

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Бик тиз үпкәләүчәнгә әйләнеп калырсыз бугай. Ничек тә белгертмәскә тырышыгыз шул хисне! Юкса... Атна ахырында яңа максатларыгыз барлыкка килер. Ни хикмәт: шундук мөмкинлекләре дә пәйда була башлар!

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Шактый ук катлаулы чор: сезне алдарга ниятлиләр сыман. Шуңа күрә таныш булмаган кешеләр белән аралашмаска тырышыгыз. Акчагызны кемдер киңәш иткән юк-барга тотмагыз – үкенүегез бар. Атна ахырында керем мәсьәләсенә кагылышлы сөенечле хәбәр көтегез.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Якын араларда бик матур үзгәрешләр көтегез. Дөрес, моның өчен байтак кына тырышырга туры киләчәк. Ярдәм кирәк булса, дустыгызга таяныгыз: һичшиксез, сезне кыенлыктан йолып калачак ул.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Үткәндәге вакыйгаларны һәм хаталарны барлау теләге туар. Нәтиҗәдә бүгенге тормышыгызны тагын да күркәмләндереп җибәрү мөмкинлекләре уйлап табылыр. Ни гаҗәп: уй-ниятләрегез инде ял көннәрендә үк чынга аша башлар.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Бу атнада кәеф-рухыгыз телтеш тидергесез булыр. Шуннан файдаланып калыгыз: бик кыен булып тоелган мәсьәләләрне хәл итәргә тотыныгыз, дус-ишләрегез белән очрашулар оештырыгыз. Парлыларның мөнәсәбәтләрне ныгытуы, ялгызларның гашыйк булуы өчен мөмкинлекләр чиктән ашачак.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Бөтен игътибарны сәламәтлеккә юнәлтегез. Юк-юк, сезнең әлеге мәсьәләдә барысы да тәртиптә, ләкин бу ыгы-зыгылы чорда профилактиканың артыгы булмаячак! Эштә мөһим проектларга алынмыйча торыгыз. Гадәттәге эшләр белән мәш килсәгез, әлегә шул җитә.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Туганнарыгыз белән мөнәсәбәтләр бигүк шәптән түгел шикелле. Аларга карата йомшаграк, «җылырак» булып карагыз әле: хәлләр шундук уңай якка үзгәреп куячак! Башыгызга борчу алырга теләмәсәгез, бурычка акча алмаска тырышыгыз.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Киләчәккә планнар коруны кичектереп, бүгенгесе белән генә яшәгез: эш-мәшәкатьләрегез болай да чиктән ашкан! Хезмәт урынында бөтен көчне биреп ярышып эшләргә туры килер. Аның каравы акчасы да, дәрәҗәсе дә булыр.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Уйлаганыгызны әйтергә курыкмагыз, юкса җитәкчегез үзегезне беркайчан да ишетмәячәк. Бер мәсьәләне искиткеч шәп хәл итеп, үзегезне гүя лотерея уенында җиңгән кеше сыман хис итәрсез. Хезмәттәшләрегезнең көнләшүен исәпкә алмаганда, барысы да әйбәт булачак.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Эш урынында теге яки бу сюрпризлар килеп чыгарга мөмкин. Коллегаларыгыз янында әлегә бик ачылып сөйләшмәгез. Гаиләгезгә игътибарлырак булыгыз – алар сезнең ярату һәм кайгыртуыгызга бик мохтаҗ хәзер. Шул ук вакытта үзегезне дә онытмагыз.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 27 гыйнвар, 2022 ел, №165/1412 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Апас районы территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга хәлиткеч тавыш хокукы белән сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү турында хәбәр итә

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 22, 26 һәм 29 статьяларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 15 һәм 18 статьяларына таянып, хәлиткеч тавыш хокукы белән, Татарстан Республикасы Апас районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләренең туктатылуына бәйле рәвештә, хәлиткеч тавыш хокукы белән, Татарстан Республикасы Апас районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасын билгеләү өчен кандидатура буенча тәкъдимнәр кабул итү турында игълан итә.

Документлар бу хәбәр басылып чыкканнан соң 6 көн эчендә, эш көннәрендә 09.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькәчә, түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420111, Казан ш., Батурин ур., 7Б й. (тәнәфес – 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькәчә). Элемтәгә керү өчен телефон: 8(843) 292-84-33.

Территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга кандидатура буенча тәкъдимнәр керткәндә, «Муниципаль берәмлекләрнең территориаль сайлау комиссияләрен, сайлау комиссияләрен, округ һәм участок сайлау комиссияләрен формалаштыру тәртибе турында методик рекомендацияләр хакында» 17 февраль, 2010 ел, № 192/1337-5 Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карарына таянырга кирәк.

КУРКУНЫҢ – ҮЗ ӨЯНӘГЕ

Бүген Җир йөзендә яшәүчеләрнең 3 проценты хәвеф һөҗүменнән (панические атаки) интегә. Пандемия чорында андыйлар саны бермә-бер артты, ди белгечләр. Кешенең күңел тынычлыгын гына түгел, саулыгын да урлаган әлеге халәт нидән гыйбарәт? Бу чирне булдырмый калу мөмкинме?

Психотерапевт, медицина фәннәре кандидаты Гүзәл ГЫЙЛАҖИЕВА хәвеф һөҗүменә бәйле төп сорауларга ачыклык кертте.

• НИДӘН ГЫЙБАРӘТ?

Хәвеф һөҗүме – контрольдә тотып булмый торган курку өянәге. Андый өянәк вакытында кешенең йөрәге чәнчи, куллары тирли, ойый. Ул тирән итеп сулыш ала алмый, әмма еш-еш сулый. Ниндидер куркыныч халәт башлана дигән хәвеф барлыкка килә. Андый чакта кеше үз-үзен тынычландырырга тырышкан саен, һөҗүм билгеләре көчәя генә бара. Әгәр мондый һөҗүм гел кабатланып торса, кешегә хәвефле тайпылыш дигән диагноз куела.

• НИ СӘБӘПЛЕ ПӘЙДА БУЛА?

Хәвеф һөҗүме нәселдән нәселгә күчә ала. Аңа стресс, талчыкканлык, бик нык арыганлык та сәбәпче була ала. Исерткеч эчемлек, наркотиклар куллану да хәвеф һөҗүме пәйда булуга китерергә мөмкин. Социаль челтәрләрнең дә йогынтысы юк түгел. Аның аша кеше башкалар тормышын күзәтеп, үз тормышыннан канәгать булмый башларга, бернигә ирешмәдем, берни эшли белмим дип үз-үзен битәрләргә мөмкин. Бу исә – хәвеф һөҗүме өчен менә дигән җирлек.

• КОРОНАВИРУСКА НИ КАТНАШЫ БАР?

Пандемия чорында мондый хәлдән интегүчеләр саны бермә-бер артты. Чир йоктырудан куркып яшәү, йоктырган очракта озак һәм куркыныч итеп авыру, шушы афәт аркасында якын кешеләреңне югалту, үзизоляция вакытында өйдән чыга алмыйча тилмерү... Болар берсе дә эзсез югалмый бит. Бар да кешенең психикасына бәрә. Шуңа күрә күпләр хәвеф һөҗүменең нәрсә икәнен нәкъ менә шушы пандемия чорында белде дә инде. Әмма аның барлыкка килү-килмәве кешенең коронавирус белән авырган булу-булмавына һич кенә дә бәйле түгел.

• ДӘВАСЫ НИНДИ?

Хәзерге вакытта антидепрессантлар белән дәвалыйбыз. Әмма аларның да теләсә кайсын эчәргә ярый дигән сүз түгел бу. Нинди дару эчәсен бары тик табиб кына билгели ала. Хәвеф һөҗүменнән интеккән кешегә ялгыш диагноз куелырга да мөмкин. Гадәттә, аның урынына кешене кан тамырлары кинәю яки остеохондроздан дәвалый башлыйлар. Шул рәвешле хәвеф һөҗүмен тойган кеше вакытында тиешле дәвасын алмаска да мөмкин. Бу чир вакытында тынычлану өчен эчә торган дарулар гына ярдәм итми.

• ҮЗЛЕГЕҢНӘН ДӘВАЛАНЫП БУЛАМЫ?

Белгечкә күренергә мөмкинлек булмаса, бу чир турында күбрәк укып, аны төптән өйрәнергә кирәк. Медитация ясагыз да, хәлегез шактый җайланыр. Гади генә күнегүләр дә ярдәм итәчәк. Әйтик, иң элек хәзерге вакытта сез күргән биш әйберне тәфсилләп тасвирлап чыгыгыз. Аннары сез хәзерге вакытта ишеткән тавышларны, кичергән хисләрне тасвирлагыз. Хәлегезнең шактый яхшырганын сизәрсез.

pixabay.com

• КАЙЧАН ЧАҢ СУГАРГА?

Төрле кешедә төрлечә булырга мөмкин. Берәүләр ике атнага бер тапкыр үзенә хәвеф һөҗүм итүдән зарланса, икенчеләре бу чиргә күнегеп, аның белән яшәргә таяләшкән була. Әмма ничек кенә булмасын, хәвефләнү кеше тормышына тискәре йогынты ясамый калмый.

• АЛЛЕРГИЯ СӘБӘПЧЕМЕ?

Аллергияле кеше еш кына хәвеф һөҗүменнән дә тилмерә дигән сүз – уйдырма. Ул аллергия аркасында да, кан тамырлары кысылу, остеохондроз, йә булмаса, бала вакытта алган ниндидер җәрәхәтләр аркасында да барлыкка килә алмый.

• НИЧЕК БУЛДЫРМАСКА?

Бу сорау белән баш ватканчы, хәвеф һөҗүменең беренче билгеләре сизелә башлау белән, шундук табиб-психотерапевтка барырга киңәш итәр идем. Вакытында чарасын күрсәң, ул дәвалауга бирешә. Ә аны булдырмыйм дип, ниндидер кагыйдәләр үтәргә тырышуның бернинди нәтиҗәсе дә булмаячак. Әйтик, кеше, хәвеф һөҗүме барлыкка килә күрмәсен дип, начар хәбәрләрне азрак тыңлый башлый ди. Бу очракта ул, чирне кисәтәсе урынга, проблемалардан качып яшәргә өйрәнергә мөмкин.

Киңәш-табыш

КАБЫГЫ ДА – ДӘВА

Мең дә бер төрле чирдән дәва саналган лимон һәрчак кул астында булса яхшы. Ул матдәләр алмашын көйләүче, тукымаларны тукландыручы С витаминына, А, B_1, B_2, Д витаминнарына, цитрусларда гына була торган Р витамины яки цитринга бай.

✓ **Ангина** вакытында телемләп киселгән лимонны авызга кабып суырасың һәм йотасың, моны сәгать саен кабатларга. Бигрәк тә лимонның кабыгы файдалы. Аны чәйнәгәннән соң, С витамины тамак төбендәге бактерияләрне үтерсен өчен, башка ризык капмый торырга киңәш ителә.

✓ **Йөткергәндә** тигез күләмдә бал, лимон согы, шикәр комы кушып кайнатасың да, ютәл башлангач, бер аш кашыгы кабып куясың.

✓ **Томау төшкәндә** борынга көнгә 5–6 тапкыр берничә тамчы лимон согы тамызасың.

✓ **Вирусларга каршы** чөгендер һәм лимон согы кушылмасы – иң яхшы чара.

✓ **Гипертониядән** интегүчеләргә тәүлеккә 3–4 тапкыр кабыгы белән ярты лимон ашау файдалы.

✓ **Баш авыртканда** лимон кабыгының ак катламын куптарып аласың һәм юеш ягы белән чигәгә куеп, берникадәр вакыт тотасың. Озакламый лимон кызарып чыгар, ә баш авыртуы бетәр.

✓ **Күңел болганганда** лимонның кабыгы белән йомшагы арасындагы ак катлам ярдәмгә килә.

✓ **Көзән җыерганда** 10 көн дәвамында иртә-кич аяк табанын лимон согы белән ышкыйсың. Сок кипкәч, оекбаш киясең.

✓ **Борын канаганда** борын тишегенә лимон согы сеңдерелгән мамык тыгасың. Кан нык ага икән, борын яфракларын бармаклар белән кысып, 3 минут тотасың. Бу вакытта маңгайга юеш салкын сөлге яки боз куярга кирәк.

Үзем сынадым

ГАСТРИТТАН БУЛЫШТЫ

Гастриттан интегәм. Соңгы арада менә шушы ысулның файдасын күрә башладым. Аның өчен көнгә ике мәртәбә, ашарга ярты сәгать кала яртышар стакан бәрәңге согы эчәргә кирәк. Бер порция сок әзерләү өчен 2–3 яхшылап юылган бәрәңгене кабыгы белән угычтан уасың. Марля аша сыгарга һәм согын шундук эчәргә кирәк. Кызыл бәрәңге согы ашказанына файдалырак, диләр. Шушы сокны бер атна эчтем. Файдасы бик тиз сизелә.

Алсу ГАЛЛӘМОВА. Апас

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ЯРТЫ КӨНДӘ – 17 БӘЛЕШ

Камыр ризыклары сату нокталары адым саен булса да, социаль челтәрләрдә милли ризыклар сатучы уңган хатын-кызларның саны көннән-көн арта. «Яратып, чын күңелдән пешергәндә үз кешеләреңне табу кыен түгел», – ди әлеге кәсепкә кереп киткән Лилия СӘГЪДИЕВА.

:: Лилия, хәзер пешерүчеләр, пешекче блогерлар бихисап. Ничек милли ризыклар пешерүгә алындыгыз?
– Белемем буенча хисапчы булсам да, һөнәрем буенча бер көн дә эшләмәдем. Курслар бетереп, пешекче булып эшләп алдым. Тик кияүгә чыгып, өч балам туганнан соң үз йортыбызда яши башлагач, каядыр эшкә чыгып йөрүне күз алдыма да китерә алмадым. Балачактан пешерергә ярата идем. Менә шул хоббием минем табыш чыганагына әйләнде. Ирем дә, балалар да бу эшкә керешүемә бик шат кына булдылар.

:: Бер көнгә иң күбе ничә бәлеш пешергәнегез булды?
– 31 декабрь көнне төшке аштан соң 17 бәлеш пешердем. Ә бавырсакка берьюлы 65 килограммга заказ биргәннәре булды. Аны өч көн пешерергә туры килде.

– Суши, ролл, пиццага өстенлек бирүче яшьләр бәлешкә заказ бирәме?
– Яшьләр заказ бирми диярлек. Бәлешне күбесенчә урта яшьтәгеләр эшкә туган көннәренә, өйдәге мәҗлесләр өчен сорый, ә бавырсакны туган көннәргә, туй һәм никахларга заказ бирәләр.

:: «Фирменный» рецептларыгызны башкалар белән бүлешәсезме?
– Бәлешнекен сорасалар әйтәм, ә бавырсакныкын әйтәсем юк. Эш рецепттан гына тормый. Бер төрле әйбер белән бассаң да, камыр төрле кешенеке төрлечә килеп чыга.

:: Үз эшләрен башларга хыялланып йөргән пешерергә ратучыларга нәрсә киңәш итәсез?
– Үз эшеңне башлап җибәрү өчен бик зур теләк һәм әлеге эшне ярату кирәк. Баштарак, әлбәттә, куркыта, борычы, тозы да артыграк яки ким булгалый. Тик бу туктап калу өчен сәбәп булырга тиеш түгел. Әлбәттә, бәлешнең итен, чәкчәкнең балын кызганмаска кирәк. Шулай ук заказны вакытында өлгертү дә мөһим.

:: Бәлеш сатып, аена күпме акча эшләргә мөмкин?
– Бәлеш сатып кына әллә ни күп эшләп булмый. Мин бавырсак, чәкчәк, кош теле, пироглар да пешерәм. Дөресен генә әйткәндә, көчәнми генә эшләгәндә ике ел чамасы элек аена чиста 30 мең сум чамасы акча эшләп була иде, хәзер исәбен алып барганым юк.

:: Пешекче булып та, сылу булып калырга мөмкин икән, дигән уй килә сезне күргәч. Ризыкның исен иснәп тә тазарабыз, ди бит пешерергә яратучы хатын-кызлар.
– Үземне формада тоту өчен дүрт ел инде спортзалга йөрим. Минем вакытым бүленгән. Гадәттә, төшке ашка кадәр ике бәлешемне пешерәм дә спортзалга йөгерәм. Хатын-кыз, эш дип, үзен онытырга тиеш түгел.

ЛИЛИЯ СӘГЪДИЕВАДАН 5 КИҢӘШ

1 Бавырсак йомшак һәм көпшәк булсын өчен, катырылган йомырка салырга кирәк. Туңдыргычта никадәр озаграк торса, шуның кадәр яхшырак. Минем йомыркалар яртышар ел саклана. Күп итеп суыткычның туңдыра торган өлешенә куям да искесен алам, яңасын куя барам.

2 Бәлеш камыры кетердәп торсын өчен үсемлек маен каймакка караганда күбрәк салырга, ә менә йомырка салмаска кирәк.

3 Чәкчәк камырын йомшак итеп бассаң, ул тәмлерәк булачак.

4 Бәлеш, бавырсак, чәкчәк камырын пешергәнче ярты сәгать ял иттерсәң, камыр яхшырак уңачак.

5 Пироглар өчен «песочный» камырны суыткычта яки бераз туңдыргычта тотсаң, ул тәмлерәк була.

Белеп тор!

Ак булсын

Вакыт узу белән кафельләр арасындагы «җөй»ләрдәге акшар саргая һәм ямьсезләнә. Аны чистартуның бер җайлы гына ысулы бар.

Бер зур пакет лимон кислотасын бер стакан кайнар су белән болгатабыз. Әлеге эремәне плитәнең барлык җөйләренә сөртеп чыгабыз. Беренче сөртүдә үк тулысынча чистармаска да мөмкин. Шунлыктан әлеге ысулны 2–3 тапкыр кулланып карарга киңәш итәлә. Җөйләр тулысынча әлеге катнашманы сеңдергәннән соң үз эшен эшли башлаячак. Ә берәздан аны кайнар су белән юып алырга киңәш итәлә. Плитәләрегез ялт итеп торачак!

Бакчачыга

ТУФРАГЫНДА ХИКМӘТ

Чаллының «Яшел блогер»ы Мария Гарәпшина үсентеләргә туфрак әзерләү буенча киңәшләрен бирде.

Үсентеләр өчен иң яхшы туфрак кибеттән сатып алганы түгел, ә үзең «ясаганы», ди блогер.

Файдалы кушылманың 15% чамасын ком, 30 процентын – туфрак белән торф һәм 50 процентын компост тәшкил итәргә тиеш. Туфракның ачылыгын киметү өчен, бераз агач көле кушарга кирәк. Компостны иләп, аны таш, чүп, яңгыр суалчаннарыннан арындырырга киңәш итәлә. Башка кушылмаларны шулай ук иләсәң яхшы.

Туфракны орлык чәчкәнче ике атна алдан зарарсызландырырга кирәк. Туфракны паразитлардан арындыру зарарлы һәм файдалы микрофлораны да үтерергә мөмкин, ди блогер. Шунлыктан туфракны салкын урынга куеп, кайнап чыккан су сибәргә, кайнап торган су өстендә тотып парландырып алырга һәм марганцовкалы су сиптерергә киңәш итә ул.

Тәмле булсын!

ЯЛКАУЛАРЧА СУШИ

Кирәк:
- ✓ *150 г пешкән дөге*
- ✓ *45 мл дөге серкәсе*
- ✓ *1/2 чәй кашыгы шикәр комы*
- ✓ *1 нори җәймәсе*
- ✓ *пешкән креветка*
- ✓ *тозы аз балык*
- ✓ *эремчекле сыр*
- ✓ *кыяр*

1. Дөгегә серкә, шикәр комы, кайчы белән туракланган нори салып болгатырга.
2. Боз катыра торган формага азык-төлек пленкасы җәяргә. Һәрбер бүлемтегенә креветка яки балык, аннары эремчекле сыр, кыяр һәм дөгеле катнашманы салырга.
3. Формадан сушины алырга һәм табынга соя соусы белән бирергә.

Мода һәм стиль

Ничек матур күренергә?

Мода артыннан куып җиту мөмкин булмаса да, стилист Эвелина Хромченконың кайбер киңәшләрен истә тоту һәр хатын-кызга файдага булыр.

- Һәр хатын-кызның өч төрле киеме булырга тиеш: үзе өчен, дуслары өчен һәм ир-атлар өчен кия торганы.
- Джинс чалбар фигураны төз, матур итеп күрсәтергә тиеш. Ялтыравыклы, чигүләрен сайламагыз.
- Тездән ике уч түбәнрәк төшеп торган итәк затлырак күренә.
- Киемдә өчтән артык төс кулланырга кирәкми.
- Гармоник образ – кара тар итәк, ак блузка, сумка-клатч һәм шпилька үкчәле туфли.
- Чәч төсегез мех киемнәр төсеннән аерылып торырга тиеш.
- Хатын-кызны кием түгел, ә үзенә булган мөнәсәбәте картайта.
- Утә күренмәле киемнәр вульгар кыяфәт бирә. Шунлыктан андый киемнәр өстеннән жакет киегез.
- Йөргәндә итәк җыерылып менә икән, димәк, бу сезнең үлчәм түгел.
- Зәйтүн һәм сазлык төсендәге киемнәр сайлаганда сак булыгыз: алар бик сирәк кешеләргә генә килешә.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

КУНАК АШАГАНҺӘР КИСӘК – САВАП

Без – кунакчыл халык. Бер минутка гына сугылдым дип килеп кергән кешене дә кадер-хөрмәт белән кунак итеп җибәрергә тырышабыз. Соңгы елларда сирәгрәк күренешкә әверелеп барса да, кунак каршылау, кунак итү – яшәү рәвешебезнең бер өлеше булып кала. Кунак каршылауның савабы нинди? Исламда кунак әдәбе нидән гыйбарәт?

«Әл-Мәрҗани» мәчете имамы Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ белән шул хакта сөйләштек.

:: Ансар хәзрәт, иң элек ислам диненең кунак каршылау, кешене кунак итүгә мөнәсәбәтенә тукталыйк әле.

– Кунакчыллык ислам динендә бик югары бәяләнә. Кунакка чакыралар икән, анда бару сөннәт гамәл булып тора. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһиссәләм: «Исламның иң яхшы күренеше ул – кешеләрне кунак итү һәм белгән кешеләргә генә түгел, белмәгәннәренә дә сәлам бирү», – дигән. Тагын хәдисендә пәйгамбәребез: «Әй, кешеләр! Кунакларыгызга басым ясамагыз. Кунак үз ризыгы белән килә һәм киткәндә хуҗаның гөнаһларын алып китә», – дигән. Шуңа күрә адәм баласы кунакны чакырудан да, кунакка барудан да оялырга, авырсынырга тиеш түгел. Шушы изгелегебез өчен Аллаһы Тәгалә әҗерен дә насыйп итә, гөнаһларны гафу кылуга, ризыгыбызның киңәю, күбәюенә дә китерә.

:: Динебез кунак кешегә һәм аны кунак итүчегә нинди таләпләр куя?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһиссәләм: «Кунакка чакыру һәм кунакка бару – сөннәт гамәл. Хәтта бу кеше нииндидер югары дәрәҗәле булмаса да», – дигән. Ягъни сине синнән түбәнрәк дәрәҗәдәге кеше кунакка чакырса да, аның чакыруын кабул итеп, аның мәҗлесендә катнашырга тиешсең. Шундый риваять бар. Ансарларның берсе, сый-нигъмәт әзерләп, пәйгамбәр белән тагын дүрт кешене кунакка чакырган. Ләкин алар артыннан тагын бер кеше ияргән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһиссәләм кунакка чакыручының ишеге төбенә килгәч, хуҗадан: «Бер кеше безнең арттан иярде. Әгәр теләсәң, аңа керергә рөхсәт ит. Теләсәң, ул кайтып китәр», – ди. Чакыручы: «Юк, юк, каршы килмим, керсен», – дигән. Шушы риваятьтән аңлашылганча, безне кунакка чакырып, безнең белән тагын бер кеше ияреп килә икән, без иң элек чакыручыга бу хакта җиткерергә тиешбез. Шул рәвешле чакырылмаган кунакны хуҗа белән алдан килештерергә кирәк.

Кунакка чакыралар икән, анда бик иртә дә, соң да түгел – вакытында килү мәслихәт. Кунакка килгәч, ишеккә өч тапкыр шакып, рөхсәт сорарга кирәк. Кунак кеше табын янына хуҗа тәкъдим иткән урынга утырырга тиеш. Аның мәҗлес азагына кадәр утыруы зарур. Шул ук вакытта хуҗага ошамый торган гамәлләр кылудан (моны ашыйм, тегене яратмыйм, бу тәмле, бу тәмсез дип мәшәкать тудыру һ.б.) да тыелырга кирәк. Хуҗалар ничек кенә кунак итсә дә, киткәндә син аларга рәхмәтеңне әйтеп, Аллаһы Тәгаләдән аларның гаиләләренә иминлек сорап, дога кылып китәргә тиеш. Мәҗлестән киткәндә иң элек хуҗадан рөхсәт сорарга кирәк. Кунактан вакытында китә белү дә әйбәт.

Ураза тоткан кешегә, аның уразасын бозып, кунакка бару килешми. Әгәр син алдан кунакка чакырулы булсаң, ул көнне уразага керү рөхсәт ителми. Бу фарыз уразасына кагылмый. Хуҗа кеше кунакны ишеккә кадәр озатырга тиеш. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Китеп барган кешене ишеккә кадәр озату – сөннәтнең бер өлеше», – ди. Кунакны ишеккә кадәр озатып, рәхмәтеңне җиткереп, аның рәхмәтен кабул итеп, хөрмәтләп саубуллашырга кирәк.

Февраль аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Сиш	05:29	07:37	14:25	16:17	18:04
2	Чәрш	05:27	07:35	14:27	16:19	18:06
3	Пәнҗ	05:25	07:33	14:29	16:21	18:08
4	Җом	05:24	07:31	14:31	16:23	18:09
5	Шим	05:22	07:29	14:33	16:25	18:11
6	Якш	05:21	07:27	14:35	16:28	18:13
7	Дүш	05:19	07:25	14:37	16:30	18:15
8	Сиш	05:17	07:23	14:39	16:32	18:17
9	Чәрш	05:15	07:21	14:41	16:34	18:19
10	Пәнҗ	05:13	07:19	14:43	16:36	18:21
11	Җом	05:12	07:17	14:45	16:38	18:23
12	Шим	05:10	07:15	14:47	16:41	18:24
13	Якш	05:08	07:12	14:49	16:43	18:26
14	Дүш	05:06	07:10	14:51	16:45	18:28
15	Сиш	05:04	07:08	14:53	16:47	18:30
16	Чәрш	05:02	07:06	14:55	16:49	18:32
17	Пәнҗ	05:00	07:03	14:57	16:51	18:34
18	Җом	04:57	07:01	14:59	16:54	18:36
19	Шим	04:55	06:59	15:01	16:56	18:38
20	Якш	04:53	06:56	15:03	16:58	18:40
21	Дүш	04:51	06:54	15:05	17:00	18:42
22	Сиш	04:49	06:52	15:07	17:02	18:44
23	Чәрш	04:46	06:49	15:09	17:04	18:46
24	Пәнҗ	04:44	06:47	15:10	17:07	18:48
25	Җом	04:42	06:44	15:12	17:09	18:50
26	Шим	04:39	06:42	15:14	17:11	18:52
27	Якш	04:37	06:39	15:16	17:13	18:54
28	Дүш	04:34	06:37	15:18	17:15	18:56

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Гөлнара Зиннәтуллина

:: Соңгы арада кунакка йөрешү, бер-береңнең хәлен белешү сирәк күренешкә әверелеп бара. Моның төп сәбәбе нидә икән?

– Бу күренешнең төп сәбәбен бер әйбергә генә кайтарып калдырырга кирәкми. Дөрес, соңгы бер-ике елда кунакка йөрешү, кунак итүләр пандемия аркасында кимеде. Әмма бу күренеш аңа кадәр дә кими башлаган иде инде. Моңа, иң беренче чиратта, кулда кесә телефоннары булу сәбәпче. Туганнар, дуслар белән социаль челтәрләр аша даими рәвештә элемтәдә тору галәмәте. Ул якының белән күрешеп сөйләшкән кебек тәэсир калдыра. Шуңа күрә кешенең туганы, дусты белән җанлы аралашу, күрешүгә ихтыяҗы калмый. Бу – зур ялгышлык. Элеккеге заманнарда әби-бабаларыбыз кунакка йөрешү, хәл белешүләрне күркәм күрә иде. Туганнар, дуслар белән җыелу ашау-эчүгә генә кайтып калмый. Шунда ук туганлык, дуслык җепләре дә ныгый. Алар белән шундый җылы мөнәсәбәттә яшәү – безнең өстебездәге бурыч. Шуңа күрә хәзерге заманда да туганнар, дуслар белән күзгә-күз очрашып сөйләшү, очрашу, кунакларга йөрешүгә вакыт тапсак иде.

:: Ни өчен кунак чакыру, кунак итү саваплы гамәл санала?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһиссәләм: «Адәмнең кунагы өчен сарыф ителгән бер дирһәме Аллаһы Тәгалә юлында сарыф ителгән мең динардан да хәерлерәк булыр. Аллаһы Тәгалә кыямәт көнендә аны мең хөрмәт белән хөрмәтләр, уттан азат итәр, җәннәткә кертер», – ди. Без бар эшебезне Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен эшләргә тиеш. Кунак чакыру, кунак кабул итү дә искәрмә түгел. Тагын бер хәдисендә пәйгамбәребез: «Мөэмин йортына кунак керсә, аның үзе белән мең бәрәкәт, мең рәхмәт килер. Аллаһы Тәгалә кунак ашаган һәр кисәк өчен йорт хуҗасына бер хаҗ, бер гомрә кылу савабын яздырыр», – ди. Шуңа күрә кунак каршылау, кунак итү – бик зур саваплы гамәл.

:: Кунак сораса, аны өч көнгә кадәр кунарга калдыру мәслихәт, диләр...

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһиссәләм: «Аллаһка вә Кыямәт көненә ышанган кеше кунагын, аның хакын белеп олыларга тиеш», – дигән. Аннан: «Аның хакы нинди?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез: «Бер көн вә бер төн, вә өч көнлек кунакчыллык. Моннан ары барысы да – сәдака», – дип җавап кайтарган. Ягъни кеше өч көннән дә артыграк кунак була икән, Ходай Тәгалә хуҗа кешене сәдака бирү әҗеренә ирештерә.

:: Кунактан кайтканда, кучтәначка хәрам әйбер биреп җибәрсәләр, ни эшләргә?

– Хәрам ризыкны ашамавың, файдаланмавыңны белә торып, бу гамәлне эшли икән, ул аңа, беренчедән, гөнаһ булып языла. Без исә, үз чиратыбызда, кучтәначкә җибәрелгән хәрам әйберне юк итәргә тиеш.

Иртән укыла торган дога

Мөселман иртәләрен уянгач, түшәгеннән «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим» дип торырга тиеш. Аннан соң шушы дога укыла:

«Әл-хәмду лилләәһилләзии әхйәәнәә бәгъдә мәә әмәәтәнәә вә иләйһил-бәгъсу вән-нүшүүр».

(Безне үлгәннән соң терелтүче Аллаһыга мактау булсын! Үлгәннән соң терелтү Аллаһыдандыр, кайту да Аңадыр.)

Бу доганы онытканда: «Саулык һәм сәламәтлек белән тагын бер көнгә керткән Аллаһыга мактау булсын! Безгә бүген дә хәерләр һәм гүзәллекләр бирсен», – дип дога кылырга мөмкин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

АЛИНӘ САФИУЛЛИНА:

«МИН НЕЧКӘ КҮҢЕЛЛЕ КЕШЕ ТҮГЕЛ»

:: Ни хәл, Алинә?
– Аллага шөкер, бер көе. Матур гына яшәп ятам.

:: Татарстанның атказанган артисты исемен алуың белән ихластан котлыйбыз. Көтелгән яңалык булдымы, әллә күктән ишелеп төштеме?
– Көткән булса да, әле аны бирерләр дип кем уйлаган! Шаккаттым. «ВТ»дан шалтыратып әйттеләр аны. Куандым, иҗатымны зурлаганнарына күңелем булды. 16 еллык хезмәтемә зур әҗер итеп кабул иттем.

:: «16 ел җырлаган өчен биреләмени ул исем?!» – дип язып куючысы да булган икән.
– Журналистларның да хайп артыннан куулары таң калдырды. Әле нинди басма диген син аны! Берәр сары матбугат булса да, исем китмәс иде. Дәрәҗәле, данлы газета! Заманында, аның язылучылар санын арттырырга дип, бушлай җырлап та йөргән, шул газетаның рәхмәт хатларына кадәр алган идем.

:: Алай да, бу эпидемия белән бәйле чикләүләр җырчылар өчен депрессиягә китәрлек булды бугай инде.
– Депрессиягә мин ковид белән чирләп терелгәч кенә бирелеп алдым. Кешеләрнең җырлар яздырып, иҗат белән шөгыльләнгәннәрен хәтта аңламас чиккә җиткән идем. Янәсе, нәрсәгә кирәк ул җыр яздыру, монда иртәгәсе көнне ни буласын белгән юк... Шөкер, ул зәхмәт калдыклары узды – үз «кәлия»мә кайтып урнаштым, күңел төшенкелеген дә юып алгандай булды. Һәр депрессиядән мин җиңел чыгам анысы, үз-үземә: «Утырып еладың, елау белән ерак китеп булмый, хәзер тор да ни дә булса эшлә!» – димен. Аның бөтен дәвасы да шул. Бары эшләргә кирәк! Ә ике аягы, ике кулы булган кеше өчен чыгып булмаслык хәлләр бөтенләй юк. Өйдә эшсез яткан хатыннарны да аңламыйм, ул минем формат түгел. Мин кырык эшем кырык якта кырылып ятканны яратам. Эшләп бетермәслек булсын ул. Менә шунда чын тәмле тормыш була.

:: Андый көчле хатыннар гадәттә ялгыз була...
– Мин үземне көчле дә дия алмыйм. Мин гадәти! Әмма бервакытта да балтам суга төшкән кебек йөрмим, һәрвакыт шөгылем бар, хәрәкәттә. Тик менә гаилә тормышым барып чыкмады – бер киселгән икмәк ялганмый икән.

:: Әллә син аңа кире дә кайтып карадың?
– Карадым шул. Баламның әтисе белән елдан артык аерым яшәгәннән соң, әнинең: «Бала әтисе белән үсәргә тиеш, баланы үз әтисеннән кала кем яратсын?» – дигән сүзләрен тыңлап, кабат кушылып карадым. Әмма шуны беләм: бер ышанычың беткән кеше белән «ә бәлки», дип яшисең, кара көн җитә калса, нишлисе булыр, дип уйлыйсың икән ул. Икең ике тараф кешесе булуына төшенгәч, киселгән икмәкнең киселгән икәненә мөһер суктым да тормышымның ул битен ябып куйдым...

:: Фатирсыз калгач, үз тырышлыгың белән фатирлы булдың. Авырлыклар сиңа көч кенә өсти диярсең.
– Мин эштән курка торган кеше түгел. Ремонт эше өчен бөтенләй үлеп китәм. Туганнардан шактый бурычка алып торырга туры килде, әмма җан биргәнгә юнь дә бирә, ди Ходай Тәгалә – бурычларымны капларлык акчаны да эшләп таптым.

– Монда инде «Син нишләп һаман кияүдә түгел?» дигән сорау туа кебек...
– Бәлки, күптән кияүдә дә булыр идем. Әмма яши-яши үземнең фәлсәфәмне булдырдым: мин бер генә яшим һәм кияүгә башаяк гашыйк булып, яратып чыгачакмын. Исе үк минеке булган ир-ат белән яшисем килә.

Блиц-сораштыру

– Нинди ризык дип үлеп китәсең?
– Манго яратам. Аннан да бигрәк, слива бугай.
– Мәктәптә укыганда «Каюм Насыйри йорты» дип йөртелгән бик матур өй янынннан узып китә идем. Башкалардан ул чатыр түбәле, ишегалды таштан, киң, иркен булуы белән аерылып тора иде. Монда гомер буена авылда торып тимер юлда эшләгән, тырышлыгы, уңганлыгы белән даны чыккан Габделгани абый Минзарипов яшәде. Ул мине безнең авылча кубарылып кипмый, гади генә каршы алды. Күрешүгә: «Нишләп бу йортны Каюм Насыйри йорты диләр?» – дигән сорау биреп ташладым. Җавап бирергә ашыкмады Габделгани абый. «Әйдә, кызым, туңганчы өйгә кер, шунда күрерсең», – диде. Башта мине болдыр ишегендәге бөгәлҗәле тимер тотка җәлеп итте. Ул уң кул уңаена ике яклап ачыла торган, төрле буйдагы кешегә уңай итеп урнаштырылган. Чоланда – өч ишек. Берсе – каҗәнкәгә керә торган (мондый урынны хәзер веранда дип атыйлар). Акрын гына ачып, бозау тиресе белән тышланган ишектән түр якка уздык. Мин өй уртасында шаккатып бастым да калдым.

Өй уртасында – аяклары сырлап эшләнгән зур түгәрәк имән өстәл. Аның ике канатын аска төшерсәң, ул кечерәк, овал сыман булып кала. Урындыкларга көмеш самавырлары тезелгән. Алар матур итеп, ап-ак, кулдан бәйләнгән түгәрәк челтәрләр белән капланган. Стеналарда – сәгатьләр, шәмаилләр. Почмакны (кухня ягы) түр яктан аерып торган ап-ак зур мичнең төнлекләре гадәттәгечә кирпеч түгел, ә матур түгәрәк металл капкачлар белән бизәлгән. Мич кашларында (бездә «пич кашы» диләр, шулай әйтсәң, матуррак ишетелә кебек) – төрле зурлыктагы керосин лампалары, шәмдәлләр. Йортның тәрәзәләре гадәттәгедән беразрак зуррак, түшәме дә биегрәк тоелды.

:: Мондый байлык Габделгани абыйга кайдан килгән?

– Габделгани абый, әйтерсең лә мине көтеп торган кебек тоелды миңа. Почмакка чакырып кертте дә, тәбәнәк сәкегә утыргач: «Кызым, минем сиңа әманәтем бар. Югалтмыйсы иде шушы байлыкны, – дип сөйли башлады. – Мин бу йортны сугыштан кайткач, өйләнеп башка чыгу өчен Шырданнан сатып алган идем. Аны миңа Каюм Насыйри туганының килене сатты, иснем онытылган инде (соңыннан ачыкладым, Разия Хөсәенова булган ул. – **Р.А.**). Шуннан кайткан дүрт әйберне – стена көзгесен, савыт-саба шкафы, каҗәнкәдәге кәнәфи һәм менә бу сәкене Каюм Насыйри үзе ясаган диделәр». Хуҗалыкта җайсызрак булса да, истәлекле сәкене Габделгани абый куллыныштан төшермәгән. Мич каршында карчыгы Хәбирә апа (Габделгани абый, нигезендә дога белән озатыр өчен, карчыгының елы тулганчы балаларына күченмичә торган) шул сәкедә бәлеш ясаган. Дөрес, еллар үтә-үтә, йортка азрак үзгәрешләр дә кертелгән.

Музей кешесе өчен иң кызык җир – чорма. Анда, гадәттә, вакыт сынавын узып, тарихка күчеп килә торган әйберләр саклана. Габделгани абыйның рөхсәтен алып, мин дә шунда менеп киттем. Монда Россиянең иң борынгы музейләрыннан саналган дәүләт музее фондларында булмаган һәм мин исемнәрен дә белмәгән әллә нинди кызык әйберләр тулып ята иде. Алар матур итеп төрле сандык, күрҗиннәргә таслап тутырып куелган.

:: Гасырлардан килгән риваятьләр, буыннан-буынга килгән гыйлем буенча хәтта берничә минуттан җиткерелү өчен әйтеп җибәрелгән сәлам дә ничшиксез утәлергә тиешле изге әманәт санала. Габделгани абыйның бу сүзләрен ничек кабул иттегез?

– Чормадан төшкәч, каралты-кура, бакча, мунча тирәләрен дә карап чыккач, башыма, музей ясарга кирәк, дигән уй оялады. «Габделгани абый, без монда музей ясасак, йортыңны сатарсыңмы?» – дигән сорау бирдем. Ул: «Ал да яса, кызым, акча кирәкми. Бер генә шартым бар: аракы эчкән кеше генә тормасын. Нигезендә чересә дә, риза», – диде. Музей ясый калсак дип, бу йорттан бер әйберне дә алмадым. Казанга килгәч, күргәннәремне Тарихи ядкәрләрне саклау оешмасы җитәкчесе, университетның тарих-филология факультетыннан сабакташым Рафаэль Вәлиевкә сөйләдем. Ул үзе барып күреп кайтты. XIX гасыр утарлары арасында тарихи яктан дөрес сакланып калганнары бик сирәк. Шундый бүләкне ничек булса да саклау һәм музей рәвешенә китерүне ул да үзенә әманәт итеп кабул итте.

Шулай итеп, туксанынчы елларда башланган акчасызлык һәм бик күп башка объектив һәм субъектив каршылыкларга карамый, 1997 елның 1 мартында Габделгани абый белән Хәбирә апа йортының кунакчыл ишекләре «Каюм Насыйри исемендәге архитектура һәм этнография музей-утары» буларак ачылды. Яшерен-батырын түгел, эш барышында күңел төшкән вакытлар да шактый булды. Шул вакытларда әнкәйнең: «Шуның кадәр дубра (добро – мал мәгънәсендә. – **Р.А.**) алып калып, Габделгани абый әманәтен ташласаң, Аллаһ каршында ничек җавап бирерсең?» – диюе исән вакытта – өндә, китеп баргач – төштә гел искә төшереп, нык булырга өндәп торды.

«Илаһи ният кылдым гыйлем өйрәнмәккә, белмәгәнемне белмәк өчен, үзем белгәннәрне белмәгәннәргә белдермәк өчен: ислам динен бакый кылмак өчен, шәригатьне тергезмәккә».
Каюм НАСЫЙРИ

:: Каюм Насыйри туган авылында озак яшиме?

– Балачак еллары Кече Шырданда үтә. Аның әтисе белән бабасы бик белемле кеше була. Синтаксис һәм этимология буенча бабасы Хөсәен язган китаптан бүген дә файдаланалар. Әтисе язган 25 китап әле дә саклана. 16 яшендә Каюмны Шырдан кешесе – Сәгыйть хәзрәт җитәкләгән мәдрәсәгә укырга бирәләр. Әмма ул туган авылына еш кайтып йөри, эзләнүләр алып бара, хәтта күп кенә хезмәтләрен дә шушында яза.

:: «Кем ул Каюм Насыйри?» дигән сорауга сез ничек җавап бирер идегез?

– Каюм Насыйри шул дәрәҗәдә киңкырлы эшчәнлек алып барган, чыннан да, санап бетерерлек түгел. Белгечләр әйтүенчә, ул – «татар әдибе», «мәгърифәтче», «олуг мөгаллим, милләт педагогы». Каюм Насыйри эшләгән өлкәләр – татар әдәбияты, татар теле, этнография, педагогика һәм методика, астрономия, математика, география, физиология, ботаника, слесарьлык эше, кулинария, журналистика...

Каюм мәдрәсәдә гарәп-фарсы телләрен өйрәнә. Яшерен рәвештә русча да укый. Соңыннан семинариядә татар теле укытучысы булып эшли. Казан университетына ирекле тыңлаучы булып йөреп, югары белем ала. Татар балаларына рус теле укытуга ныклап керешә. Соңгы елларда ул үзен язучылык һәм фән эшенә багышлый. Татар халык әдәбияты һәм культурасы буенча материаллар җыеп, Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте карамагына тапшыра бара. Аның үзе исән вакытта гына да татар һәм рус телләрендә төрле зурлыктагы 40лап китабы дөнья күрә. Каюм бабай карта сызып, аларны үзе чыгарып килгән календарьларга урнаштырып бара, авыллар тарихын өйрәнә. 1881 ел календарендә Казан губерниясенең бөтен авылларын күрсәткән карта эшләп бастыра. Берничә музыка коралында уйный белә...

:: Ничек уйлыйсыз, музейга килгән туристлар, экспонатларны карап, сөйләгәннәрне тыңлап, олуг галимебез турында тулы мәгълүмат алып китә аламы?

– Халык әйтмешли, камиллеккә чикләр юк. Музейның байлыгы арта тора. Иң мөһиме, якташлары битараф түгел. Кадерен беләләр. Бигрәк тә шунысы сөенечле.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сорау – җавап

Ут сүнсә, нишләргә?

«Татэнергосбыт» белгечләре халыкны кызыксындырган сорауларга җавап бирүне дәвам итә.

:: Вакытында түләмәгән өчен электр утын өзделәр. Миңа хәзер нишләргә?

Шәхси йортта яшәүчеләргә:

электр энергиясе өчен бурычны тиз генә түләп, квитанциясен «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең клиентларга хезмәт күрсәтү офисына яки компаниянең үзегезгә якын филиалының электрон почтасына юлларга кирәк.

Бурычны, өйдән чыкмыйча гына, «Татэнергосбыт»ның мобиль кушымтасы һәм сайтындагы шәхси кабинет аша, Татарстан «Дәүләт хезмәтләре» порталы, банкларның мобиль кушымтасы аша түләргә мөмкин.

Ә инде өйдән түләү мөмкинлеге булмаса, «Татэнергосбыт»ның клиентларга хезмәт күрсәтү һәм компаниянең территориаль участоклары офислары кассасында (адреслары компания рәсми сайтының «Контакты» бүлегендә күрсәтелгән), «Татарстан почтасы» элемтә бүлегендә, теләсә кайсы банкта, шулай ук банкоматта түләргә.

Бурычны каплагач, клиентларга хезмәт күрсәтү офисында электр энергиясен өзү һәм аңа тоташтыру чыгымнарын каплау өчен, квитанция алырга һәм аны үзегезгә уңайлы ысул белән түләргә:

✓ квитанциядә күрсәтелгән реквизитлар буенча, банкларның онлайн сервислары аша;
✓ теләсә кайсы банк офисына барып;
✓ квитанция буенча «Татарстан почтасы» бүлекләрендә;
✓ «Татэнергосбыт»ның клиентларга хезмәт күрсәтү һәм территориаль участоклары офислары кассасында.

Шуннан соң клиентларга хезмәт күрсәтү офисы хезмәткәренә бурычны түләү һәм чыгымнарны каплау турында квитанцияләрне тапшырырга. Хезмәткәр, квитанцияләр нигезендә, «Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенә электр энергиясен кабат бирә башлауга заявка җибәрә.

Күпфатирлы йортларда яшәүчеләргә:

электр энергиясе өчен бурычны түләгәч, квитанциясен «Татэнергосбыт»ның клиентларга хезмәт күрсәтү офисына яки компаниянең үзегезгә якын филиалының электрон почтасына юлларга кирәк.

Шуннан соң офис хезмәткәреннән шәхсән яки телефон аша электр энергиясен өзү һәм аңа тоташтыру чыгымнарын каплау өчен нинди оешмага мөрәҗәгать итәсен ачыклау шарт. Аның ике төрле ысул белән түләргә мөмкин:

✓ « Татэнергосбыт» электр энергиясен өзү/тоташтыру хезмәте күрсәтүче белән килешүгә ия булса, клиентларга хезмәт күрсәтү офисына;
✓ «Татэнергосбыт» электр энергиясен өзү/тоташтыру хезмәте күрсәтүче белән килешүгә ия булмаса, үзегезнең идарәче оешмага барып түләргә кирәк.

:: Бурычны түләгәч, электр энергиясе ничә көннән соң бирелә?

– Бурычны тулысынча түләп, өзү/аңа тоташтыру чыгымнарын каплаганнан соң 2 календарь көне эчендә электр уты яңадан бирелә.

Хөрмәтле клиентлар! Сорауларыгыз булса, Элемтә үзәгенең бушлай телефонына (8-800-200-25-26) шалтыратыгыз.

ЗИРАТКА АЛЫП КАЙТ...

Картлар йортында яшәүче Салихҗан абый авылдашы Алсуга шулай дип шалтыраткан. Күпнә әллә ничә шалтырата. Сүзе бер – мине зиратка алып кайтыгыз! Бабайның ни әйткәнен аңламаган Алсу ханым, аптырап, картлар йортына шалтырата. Алар аңлата: бабайның авылга кайтасы килә...

Гыйниятуллиннарның бик мәшәкатьле чагы була. Бер ел элек йортлары, каралты-куралары янып көлгә әйләнгәч, кеше өендә торып, йорт җиткереп бетергән мәлләре. Әле ярый авылдашлары, райондашлары ярдәм итә үзләренә. Өсләренә кияргә бер алмаш киемнәре дә булмый. Гаиләдә дүрт бала, иң кечкенәсенә 1,5 яшь була.

– Аллаһы Тәгалә безне янгында исән калдырып, аннары безгә бабай җибәреп сынап карагандыр, мөгаен. Йорт-җире янган кешене бик аңлыйм мин. Иң кыен чаклар иде ул. Балаларым үз киемен сорап елый, кешенекен кимиләр. Үземнең дә кияр киемем юк иде. Шөкер, авырлыкны күтәрә алдык. Ә инде бабайга килгәндә, без аны тәрәзәсендә – челтәре, утырырга урындыгы булмаган йортка алып кайттык. Хәлен генә белергә барган кешеләр идек бит югыйсә, – ди Алсу ханым.

Салих абый Сарман районында туа. 18 яше тулгач, армиягә китәм дип йөргәндә, комбайнга кулын кыстыра. Шуннан гариплегеннән читенсенеп кала, өйләнергә дә уйламый. Гомере буе электрик булып эшли. Язмыш аны Зәй районының Сармашбаш авылына китерә. Ул шунда яши башлый. Алсу апалар белән шунда якыная. Бервакыт Салих абый бармакларын өшетә. Табиблар аларны саклап кала алмый. Шуннан соң ялгыз яшәү тагын да кыенлаша. Ашарына пешерә алмагач, үз теләге белән картлар йортына китә. Анда ун ел яшәгәч, туган җирен сагыну җиңә...

– Картлар йортыннан безгә бабайны 1 айга бирделәр, – дип сөйли Алсу Гыйниятуллина. Янәсе, кунакка кайта. «Калдырмагыз мине!» – дигәненә түзәрлек түгел иде. Йөрәгемне тыңлап, алып чыгып киттем. Бер айга гына бит, аннары илтеп куярбыз, дибез. Сарман районына кергәч, Салих абый җырлап җибәрде. Аннан үксеп елый башлады. Шулкадәр сагынган иде ул үз җирен. Ул елый, мин елыйм. Әнә шулай өйгә кайтып җиткәнне сизмәдек тә...

Салих абый үзе сорап кайтса да, беренче атналарда гаиләгә ияләшә алмый. Алсу апага да, үзенә дә кыен була. Китәр вакыты җиткәч, алар бер-берләренә якынайганын аңлый. Бабайның китәсе килми, гаиләнең – җибәрәсе. Инде нишләргә? Алсу ханым районның социаль яклау бүлеге хезмәткәрләреннән республикада өлкәннәрне тәрбиягә алу программасы эшләвен белә. Шулай итеп, бабай аларда яшәп кала. Биш елдан артык бергә инде алар.

– Олы кешегә бер җылы сүз җитә бит! Һәрнәрсәнең хикмәте бар. Тавык ите пешергәч, мин аңа ботын бирәм. Сөенә инде шуңа. Бәрәңгене бик ярата. Йомырканы көн дә ашый. Хәзер инде Салих абый үз кешебезгә әйләнде. Балаларым да аның өчен нишләргә белмиләр. Ирем дә, әйдә, бабай, чәй эчик дип кенә тора, – ди Алсу ханым.

Балалар дигәннән, өч малай янына бик соңлап кына кыз да алып кайта алар. Әнә шул кызчык бабай өчен аеруча үлеп тора. Улларының икесе гаилә корырга өлгергән инде. Өченчесе Әлмәттә медицина көллиятендә белем ала. Атна саен бабайны мунча кертү – малайлар өстендә. Алсу ханымның да, өйдә олы кеше булгач, күңеле тыныч.

– Мәдәният йортында эшләгәч, гел өйдә утырып булмый. Кайчак ипи пешерергә куям да, фәлән минуттан сүндерерсең дип әйтеп калдырам. Бабаем, мин әйтүгә, урындыгын күтәреп, газ янына килеп утыра. Вакыты җиткәч, сүндереп куя. Әле мин кайткач, зарланган да була. Күнозын ипи пешердем, дип шаярта. Камыр күперә башласа да, эченә уклау куям да, бабаемны сакка калдырам. Кабарган саен, төртеп төшер дим. Рәхәт аның белән. Шулай бергәләп гомер итәбез инде, – ди. – Салих абыйның – үз бүлмәсе, үз телевизоры. Рәхәтләнеп ял итә. Шөкер, үз аягында. Беркемгә комачау итми. Аның өчен күп итеп газеталар алдырабыз. «ВТ»ны бер хәрефен калдырмый укып бара. Укыганнарын безгә дә сөйли. Күңелле яшибез.

Салих абыйның хәлен районның социаль яклау бүлеге хезмәткәрләре дә белешеп тора. Әле менә туган көне белән котлап киткәннәр. Бабайга 77 яшь тулган.

– Бабай тәрбияләү – кешегә сөйләп мактанырлык әйбер түгел инде ул. Күңел эше. Без дә бит бабай алыйк дип бармадык. Димәк, шулай язган булган. Әмма алып кайтуыбызга бер дә үкенмибез. Кеше рәхмәтләре йөртә безне. Ә Салих абый ул сүзне кызганмый, – ди Алсу ханым. – Йөрәгегез куша икән, күңелегездә кемнедер бәхетле итү хисе яши икән, өлкәннәрне сөендерегез. Аларга үз туган ягы, торган җире, аның туфрагы, суы бик газиз. Әнә шул хистән мәхрүм итмәскә иде үзләрен.

Кайсыгызның кулы җылы?

Күңел яхшыны көтә

Редакциягә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләр шактый. Казанда яшәүче Регина безне социаль челтәрләр аша эзләп тапты. Туганына ярдәм итүебезне сорый. 10 айлык сабыйга ярдәм кирәк.

...Язмыш Валентина белән Рөстәмне моңарчы да сыный. Алар, күп хәсрәтләр кичереп, ятимлектә үсәләр. Бер-берләрен табып, тормышның кадерен, яшәүнең ямен аңлап яши башлагач, гаиләләренә хәсрәт килә. Кечкенә уллары Искәндәргә 5 ай тулгач, аңарда куркыныч һәм сирәк очрый торган генетик авыру барлыгы ачыклана.

– Барыбыз өчен дә зур хәсрәт бу, – ди Рөстәмнең туганнан-туган сеңлесе Регина. – Абыебыз кечкенәдән әтисе белән генә үскән. Әнисен ана хокукларыннан мәхрүм иткәннәр. Шуңа да минем әнием Рөстәм абыйны үз баласыдай күрә.

Бергә яшибез. Киленебез Валентина да – күпне күргән кеше. Әти-әнисенең кайдалыгын да белми хәтта. Ул Лаеш балалар йортында тәрбияләнгән.

Менә шушы ике ятим бала гаилә корып җибәргәч, йөзләрендә елмаю барлыкка килә. Беренче кызлары Динарага карап сөенүләр! Тигез, матур тормышта яшәү алар өчен сөенеп туймаслык хәл була. Тик кечкенә Искәндәрнең биш ае тулгач, кинәт кенә гәүдәсе йомшарып китә. Республика балалар клиник хастаханәсендә тикшерелгәч, диагнозны раслау өчен анализны Мәскәүгә җибәрәләр. Ике айдан хәбәр килә: Искәндәрдә – арка мускуллары атрофиясе дигән авыру.

Хәзерге вакытта Искәндәр әнисе белән Республика балалар клиник хастаханәсендә дәвалана.

– Табиблар ничек кенә тикшермиләр. Бик күп документлар җыябыз. Табиблар да балама ярдәм итәргә тырыша, – ди Валентина. – Безнеке кебек диагнозлы балаларга Мәскәү фонды ярдәм оештыра. Без дә ул фондка мөрәҗәгать иттек. Тик күңел курка. Чиратыбызны көтеп өлгермәбез кебек. Баланың язмышын бер укол хәл итәчәк. Әмма аның бәясе без күтәрә торган түгел. Аның өчен 121 миллион сум акча кирәк. Искәндәргә кадәр шул уколны көтүче дүрт бала бар. Сабыем шул уколны көтеп җиткерә алсын иде дип телибез.

Искәндәрнең хәле начараеп китмәсен өчен, ЛФК күнегүләре ясатырга кирәк икән. Аның өчен махсус инструктор чакыртырга, аңа акча түләргә кирәк. Шулай ук өйгә кайткач, сабыйның бүлмәсенә һава чистарта торган дымландыргыч, ингалятор, утырып торыр өчен махсус урындык, пульсын контрольдә тотарга, кандагы кислород күрсәткечен белергә махсус аппаратлар кирәк. Өйдәге инфекцияләрне бетереп торыр өчен лампа да куярга кушалар. Әмма бу гаиләнең әлеге кирәк-яракларны алыр өчен мөмкинлекләре юк.

– Улым авыру булгач, мин аны бер минутка да ташлап китә алмыйм. Гаиләдә бары тик ирем генә эшли. Әле бит олы балам да бар. Шуңа да мәрхәмәтле кешеләрдән ярдәм сорыйм. Гаиләбезгә килгән хәсрәткә битараф булмасагыз иде, – ди Валентина.

Кечкенә Искәндәргә ярдәм итәргә теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизитлары: әнисе Валентина Александр кызы Королева исемендәге Саклык банкы картасы номеры: ***5228 6005 4117 1353.*** *ВТБ банкы картасы номеры:* ***6769 0700 4614 0258.***

Гөлгенә ШИҺАПОВА

НӘКЫЙП КАШТАНОВ:

«НӘСЕЛЕБЕЗ БЕЛӘН АЧЫШ ЯСАРГА ОМТЫЛУЧЫЛАР БЕЗ»

Язучылар табибы, балаларның дусты, тарихчы. Болар барысы да – Нәкыйп КАШТАНОВ турында. Кемдер аны шигырьләре, балалар өчен хикәяләре өчен үз итсә, күпләр өчен ул – алыштыргысыз пульмонолог та. Ел башында 80 яшен тутырган язучы, иҗат итүдән бер көн дә туктаганым юк, дип белдерә.

:: Чит ил әдәбиятында да, руста да башка һөнәр ияләре булган язучылар күп. Әйтик, Чехов, Булгаков – табиблар, Джек Лондон кем генә булып эшләмәгән. Татар әдәбиятында башка һөнәр үзләштергән язучылар бик сирәк, юк дәрәҗәсендә. Моның сәбәпләре нәрсәдә икән?

– Бу хакта уйланганым юк. Миңа калса, башка һөнәр үзләштергәннән соң әдәбиятка килгән кешенең тәҗрибәсе зуррак, бармактан суырып язмый инде ул, һәрхәлдә... Шәхсән мине табиб булу күзәтүчәнлеккә өйрәтте, фән өлкәсен дә, әдәбиятны да яраттырды. Фундаменталь ачышлар ясарга этәрде.

Мәсәлән, үпкә ялкынсынуы дигән чир бар. Мин аны өйрәнеп, 2016 елда китап бастырып чыгардым. Шушы вакытка кадәр аның килеп чыгуының сәбәпләре өйрәнелмәгән иде. Ә мин әлеге чир белән төнлә гырлаучылар чирли дим. Гырлаучының тын алуы бик көчле, бронхларга ят кисәкчекләр, мәсәлән, теш арасына кысылып калган ит кисәкчекләре эләгүен көт тә тор. Күзәтүләр шуны күрсәтте дә: авыручылар гырлый, кичен тешен чистартмый. Тешне генә түгел, теш арасын чистартырга кирәк, күпләр моны эшләми. Шундый очрак та булды: гырлаучы бер кешенең үпкәсенә теш коронкасы төшеп утырган иде. Шулай итеп, сәбәпләрен дә ачыкладым, булдырмый калу юлларын да яздым.

:: Соңарып булса да, әдәбиятка килү сәбәбе нәрсәдә?

– Мәктәптә укыганда яза идем мин. Ул шөгыльне калдырып торырга туры килде. Ни өчен дисәң, төрле эшләрдә эшләргә туры килде. Әстерханда балык тоттым. Гаҗәеп матур урыннар иде ул. Идел тармаклары буенда ике метр ярым биеклектәге чакын үсә анда. Шул чакынны өй салуда да файдаланалар, идәнгә дә җәяләр, кеше җирләгәндә астына куеп калдыралар. Тормыш чакынга бәйләнгән анда. Камыш дисәң, камыш түгел, буынлы үсемлек инде ул. Балык сезоны тәмамлангач, консерв заводында эшләдем, шуннан – Уфа кирпеч заводында. Аннан армиягә алдылар. Учебный отрядта 8 ай шөгыльләнгәч, очраклы рәвештә Архангельскидагы диңгез флотына эләктем. Укыганда Каштанов фамилияле ике егет идек без. Мине Мәскәү егете белән бутаганнар. Капитанга ошадым, ахрысы, мине кире җибәрмәде, документларны гына соратып алдылар.

:: Каштанов фамилиясе сирәк очрый торган бит әле.

– Тумышым белән Чуашстаннан мин. Бабайлар әйтүенчә, фамилия «Куштан» дигән кушаматтан килеп чыккан. Безнең якта «куштан» төшенчәсе сәясәткә дә бәйле түгел, тискәре мәгънәдә дә йөрми. Сәгъдетдин атлы саудәгәр бабамның ике катлы куш йорты, унбер баласы булган. Саратов гармунында уйнап, җырлаган, диләр. Бөтен авыл ишетсен дип калкулыкка менеп уйнап җырлый торган булган. Ыспай киенеп йөргәнгә, уйнап җырлаганга, «Куштан» дигән кушамат кушканнар аңа.

:: Әдәбиятка тартылуыгыз аңлашыла, ә медицина? Бөтенләй капма-каршы тармаклар бит.

– Мин кечкенәдән ачыш ясарга хыялландым. Шуңа диңгез флотында хезмәт иткәндә, я Мәскәү авыл хуҗалыгы академиясенә (чөнки эти агроном булып эшләде), я медицина юлыннан китәм, дигән карарга килдем. Әтидә дә кеше булдыра алмаганны эшләргә омтылыш бар. Мәсәлән, авыл комлыгына урман утыртты. Бер чакрым озынлыктагы шушы җирдән, бераз җил чыкса, ком бураны күтәрелә иде. Урман үскәч, ком түзгымый башлады.

Шулай итеп, укырга ачыш ясарга дигән максат белән

Илдар Мөхәммәтҗанов

кердем. Аның өчен Архангельскида эшләгән чакта ук ярда торганда әзерлек курсларына йөрдем. Физиканы, рус телен ныгыттым. Нәтиҗәдә химиядән «бишле», физикадан «дүртле» алдым. Шушы ике фән миңа конкурстан тыш үтәргә мөмкинлек бирде.

:: Ничек уйлыйсыз, хәзерге табибларда белем дәрәҗәсе ничек?

> Ул чактагы белем сыйфаты белән хәзергесе җир белән күк арасы кебек. Бөтен өлкәләрдә дә шулай. Әмма шул ук вакытта талантлы яшь белгечләр дә юк түгел. Медицинаны алсак, безне фәннең йөзек кашлары, чын профессорлар укытты. Әйтик, мин – Малкин укучысы. Фән юнәлешенә нәкъ менә шушы кеше алып кереп китте. Тырышканны күрә, ялкаулыкны яратмый иде.

Менә син, әдәбиятка кереп китүегез гаҗәп, дисең. Ул чактагы укыту системасы өчен бу бер дә гаҗәп нәрсә түгел. Ник дигәндә, медицина институтында гуманитар факультет да булдырдылар. Анда журналистика бүлеге дә бар иде. Бу табиблар үзләре турында яза һәм сөйли белсеннәр өчен эшләнде. Мин журналистика факультетында ике ел укыдым. Шуннан медицина темасына радиоларда чыгыш ясый башладым, матбугатта да актив язышу башланды.

1991 елда Язучылар берлегенең балалар әдәбияты бүлеге комиссиясе әдәби әсәрләремне карады. Анда коллектив җыентыкка мине дә кертергә дигән карар чыгардылар. Мин исә аерым китап чыгару турында сорадым. Кечкенә генә, дәфтәр калынлыгы гына беренче китабым чыкты.

:: Балалар әдәбияты белән дуслашу ничек булды?

– Ләбиб Леронның җиңел кулы белән «Салават күпере»нә яза башладым. Подписка вакытында исә журналга язылуга өндәүдә «Нәкыйп Каштановның хикәяләре дә басылачак» дигән җөмләне күрдем. Исемемне реклама сыйфатында кулланганч, күрәсең, яхшы язганмындыр.

:: Шулай да балалар күңеленә үтеп керер өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк?

– Бала буш сүзне, бармактан суырып язганны яратмый. Авыр телле булырга да ярамый. Кайчак балалар өчен язылган китапны уку өлкән кешегә дә авыр була. Теле шулкадәр авыр. Балаларга дип үзләре турында язалар микән инде... Мин җиңел тел белән, күргәнне, белгәнне генә язарга яратам. Хикәяләр еш кына күзәтүләрдән туа. Мәсәлән, 40 ел элек Казахстанга сәяхәткә бардык. Ул якларда кызыл туфрак, тирә-якта ташлар. Күзәтүләр нәтиҗәсендә «Үсә торган ташлар» дигән хикәя туды. Күзәтү дә, фәнни нигезе дә бар инде аның. Дөрес, хикәя язам дип, бервакытта да махсус күзәтеп йөргәнем булмады. Үзеннән-үзе шулай килеп чыга.

:: Тагын нинди кызыксынуларыгыз бар?

– Күп инде алар. Медицина өлкәсенә кире кайтсак та, бездә башлыча авыруны, билгеләрен юкка чыгару өчен дәвалыйлар, әмма күп чирләрнең сәбәбе әле дә ачыкланмаган. Сәбәбен белсәк, без бит киләчәк буыннарда бу авыруларны булдырмый кала алыр идек. Мин кайбер чирләрнең сәбәпләрен таптым, әмма эшлисе эшләр бик күп. Тарихны саклап калу һәм киләчәккә җиткерү буенча да башкарасы эшләр шактый. Бу кызыксыну безнең нәселдән киләдер, дип әйтсәң дә була. Әтидә дә бар иде ул, Зәйнәп апа да шактый эш эшләде. Кешеләр турында очерклар язды, белгән, өйрәнгәнен кәгазьгә төшереп калдырды. Әти исә сугышта йөргәннәрен, үзе белгән кадәр нәсел турында мәгълүмат, колхоз тормышы, анда безнең нәселнең эшчәнлеген язып калдырды. Ул бәетләрне дә шактый җыйган иде. Хатларында безгә багышланган шигырьләр, җырлар язылган. Әти сугышка 1942 елда алынган булган. Болар барысы да шул юнәлештә тагын да материал тупларга этәрде. Авыл тарихы китабына мәгълүмат кырык ел җыелды. 854 битлек авыл тарихы китабы әзер булып, ел басылып чыкты.

:: Бу өлкәдә дә яңалык керткәнсез бит әле сез.

– Әйе, минем бу китапның кешеләргә ни дәрәҗәдә кызыклы булуын беләсем килде. Шуңа күрә эш барышында ук подписка үткәрдем. Мөгаен, мин беренче шундый кеше булганмындыр. Язылган кешеләр барысы да китап чыксын өчен үзләреннән матди ярдәм керттеләр. Төп иганәчеләр энем Камил, уллары Руслан, Ринат булдылар. Китапта авылның килеп чыгышы турында документаль мәгълүмат, һәр чорда авылда булган вакыйгалар, кешеләр, аннан чыккан шәхесләр турында очерклар, фольклор материал, авылда үстерелгән үсемлекләргә кадәр бирелгән. Язучы Фәтхи Бурнашның, академик Миначевның да безнең нәселгә караву ачыкланды.

:: Сезнеңчә, татар теленең киләчәге бармы?

– Әле менә сезгә килгәндә метрода китап укып барган кешене күрдем. Киләчәктә дә китап укучы да, ана телен белүче дә булачак. Мин – оптимист. Оптимизм – озын гомернең нигезе дә ул. Замана үзгәрүчән. Бүген вазгыять шушылай, иртәгә бөтенләй башка төрле булырга мөмкин. Шуңа күрә иҗат итәргә, булган әсәрләрне чыгарырга, халыкны китапка ымсындырып торырга кирәк. Китаплар хәзер бигрәк тә матур чыга бездә. Мин табиб булып ике ел гына эшләмим. Эшләгән чорда пациентлардан, без сезне укып үстек, дигәнне еш ишетә идем.

Хәер, эшләүдән туктасам да, язучылар үзләренең докторы дип санагач, кешеләргә ярдәм итүдән туктаганым юк. Ярдәм итеп, хәрәкәтләнеп, алга максатлар куеп яшәргә язсын.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Дәвамы. Башы 2021 елның 10 декабрь, быелның 21 гыйнвар саннарында

– Каракай әби, мин үләм инде. «Духтырлар да, инде яшәмәс, үлә, дип чыгардылар, – диде Инсаф, мине әтиләргә китереп куйганда. – Өйләнәм, – диде. – Синең үлгәнеңне көтеп тора алмыйм, – диде. – Гомерем үтте чирле хатын белән, ирләр сауны ярата, хатыннар байны ярата», – диде. Тәрәзәгә капланып карап калдым. Атлар җигепләр, тарантаска утыртыплар алып кайтты яшь хатынын. Мин үлгәнне дә көтмәде. Озак тормас идем инде, әзрәк көтсә шунда. Мине бит у налтым тулганчы ук урлап алып кайтты. Мин бит аларга килгәнче сау-сәламәт идем. Матур идем. Инде балам кала. Әти дә карт, әни дә үлде. Үзем дә ятимлектә үстем. Ни эшлим, нихәлләр итим? Баламны кемнәр карар? Бу хатынны бик усал, диләр. Әле үз улы да бар икән. Бигрәкләр имансыз булды Инсаф. Бер көн рәхәт күрсәтмәде. Ирсез хатыннар күп, барысының да ишеген какты. Мине генә сөймәде. Сәетемне тапкан көнне дә кайтып кыйнады. Түбән өйгә төртеп төшереп, ике сәгатьтән соң гына ачты, бала елаганга түзә алмагач кына. Әнисе дә гел котыртып торды. Мине аңа тиң дип санамады. Алар бай, без хәерче, имеш. Нәрсәгә миңа аларның байлыгы? Шуннан өзлектем. Кеше була алмадым. Аның өстенә җүнләп ашарга бирмиләр. Эт көнендә яшәдем инде.

сап-сары бите салкын иде. Сәетнең әнисен кочагына аласы, җылытасы килде. «Әни җаным, туңгансың ич. Әнә, битләрең нинди салкын. Әни, әйдә өстеңә бабайның җылы толыбын ябыйк. Җылынырсың», – диде малай, өстенә нинди хәсрәт ишелеп төшкәнен аңламыйча. Әнисенең баш очында тәсбих тартып утыручы Каракай әби малайны, кочаклап, мич артына алып кереп китте. Әбинең каракучкыл бите буйлап күз яшьләре тәгәри, үзе, малайны тынычландырырга теләп:

– Әйдә, улым, безгә керик, кайнар чәй эчәрсең. Әниең китте инде, улым. Аның җаны күбәләк булып күккә ашты. Ул: «Минем улым еламасын, ул еласа, миңа бик читен булыр», – дип, сиңа өстән карап тора. Елама, улым, үсәрсең, Алла кушса.

Малай шунда гына әнисенең үлгәнлеген, үзенең дөм ятим калганлыгын аңлап алды. Әбинең кулыннан ычкынып китеп, әнисенең җәсәденә ташланды.

– Китегез, барыгыз да чыгып китегез. Әни йоклый гына ул. Сез китсәгез, ул уяначак, – дип, ауный-ауный еларга тотынды. Бабасын чакырып керттеләр. Бабасы, әкрен генә килеп, Сәетне идәннән күтәреп алды.

– Балам, ятимнәр калдык шул. Нихәл итәсең? Аллаһы Тәгалә бәндәсенә үзе күтәрә алмас хәсрәт бирмәм, дигән. Әниеңнең гомере кыска булды. Шул мәртәт Инсаф кына башына җитте баламның. Әйдә, Каракай әбиеңнәргә кереп тор. Ату бик авыр булыр, – дип, Сәетне киендереп алып чыгып китте.

РАВИЛӘ ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ

ЯЛАНТАУГА АЙ КУНГАН

(БӘЯН)

– Йә Ходаем, үзең кичер бәндәләреңне. – Миңлебикә түти балкашык белән Хәятнең авызына су салды. – И җаным, синең нинди тормышта яшәгәнеңне бөтен авыл халкы белде инде. Тик без нишли ала идек соң? Кәнсәләргә барып әйтсәң, үзе нәчәлник. Башыңны өтермәндә черетер. Ул имансыздан ни көтәсең? Йә, балам, кайгырма, терелерсең, Алла кушса. Менә шулпа алып кердем, кап әле.

– Юк, Каракай әби, кабасым килми. Мин сизәм: тиздән өзелермен. Әнә улыма... Каракай әби, Сәетемә күз-колак булыгыз инде. Әти янына кергәләп йөр. Бүген шундый матур төш күрдем. Әнине. Имеш, бүлнистә ята икән. Мин хәл белергә килгәнмен. Авыруларның һәммәсен болынга чыгарып куйганнар. Караватларда яталар. Ап-ак чыбылдык эчендә ята болар. «И әни, – дим, имеш. – Мин сезне эссе, тынчу бүлмәдә ятасыз дип торам, ә сез нинди җиләс, матур болында ятасыз икән». Минем, Каракай әби, андый чәчәкләрне, андый яшеллекне беркайда да күргәнем юк иде. Анда кошлар да үзенчә бертөрле моңлы итеп сайрый. Үзләре шундый матурлар! Шаккатмалы. Әни әйтә: «И кызым, монда шундый рәхәт! Әйдә тау астына чишмәгә төшеп меник», – ди. Әни авырмаган да кебек. Җәһәт кенә торды да, икәү чишмәгә төшеп киттек. Андагы матурлык! Әни үзе чишмә читендәге челтәрле эскәмиягә барып утырды, мине су эчәргә җибәрде. Ул суның тәмлелеге! Су эчеп килгәч, мин әнигә әйтәм: «Әни, әйдә меник инде, – дим. – Сумкамны сестралар янында калдырган идем, иплек-тозлык акчасы да бар, югалтсам, Инсаф үтерер», – дим. «Кызым, мин шушында утырып көтеп торам, иртәгә бөтенләйгә минем яныма килерсең, монда бик рәхәт, кызым. Бик интектең инде», – ди әни. Мин әнигә: «Ярар, килермен, әни», – дип хушлашып, сестралар янына мендем. Алар барысы да озын күлмәктән. Чәчләрен яулык астына җыйнап тыкканнар. Үзләре гел елмаеп кына торалар. Гел кычкырып тора торган сестраларга охшамаганнар. Мин аларга: «Минем сумкамда бераз акчам да бар иде, югала күрмәсен, ату ирем үтерер», – дим. Алар, елмаеп: «Курыкмагыз, апа, монда акчаның кирәге юк. Монда акча йөрми», – диләр. Шуннан уянып киттем. И-и, бер дә уянасым килмәде, Каракай әби, шунда гына каласым килде. Әллә җәннәтне күрдем микән мин? Әни: «Иртәгә килерсең, бөтенләйгә», – диде бит. Вакыт җиткәндер инде, дип, күз яшьләрен арык кул аркасы белән сөртте әнисе. Шуннан арып-талып йокыга китте.

Миңлебикә түти каракучкыл кулларын күтәреп дога кылды. Яшь хатынны җәлләп елый-елый чыгып китте. Чыкканда, Сәетнең башыннан сыйпап, кесәсеннән бер кәнфит алып бирде. «Мә, улым, бигрәкләр бәхетсез бала булып тугансың, Аллаһы Тәгалә сине ташламасын. Кичен кереп, ясин укырмын, бүгеннән калмас, күкрәге белән генә сулый. Үлем алдыннан кеше шулай җиңеләеп китә», – дип, бабасы белән саубуллашты. Бабасы да, яшьле күзләрен Каракай әбигә күрсәтәсе килмичә, читкә борылды:

– Аллага тапшырдым, язмыштан узмыш юк, Миңлебикә кордаш.

Иртәгесен Сәет йокыдан уянганда, әнисе идән уртасындагы урындыкларга куелган колашага сузып салганнар иде. Тирәягына күрше-күлән, туган-тумача әбиләр җыелып, тәсбих тарталар, елашалар. Әйдә әллә нинди тынлык. Сәет торып басты. Әкрен генә әнисе янына килеп, битеннән сыйпады. Әнисенең

Әнисенең җеназасын капка төбенә чыгарып куйгач кына, соңгы тапкыр күреп калсын дип, Каракай әбинең кызы Фатыйма апасы аны урамга алып чыкты.

– Әйдә, үскәнем, – диде тәмле телле Фатыйма. – Әниең белән хушлаш! Бигрәкләр ятим калдың инде, үскәнем. Ничекләр гомер итәрсең? Бабаң да бик картайды, – диде ул.

Инде әнисенең җеназасын җиргә куйганнар. Солтан бабай моңлы итеп җеназа догасы укый. Җыелган халык лышык-лышык елый. Капка төбе әллә ничек шомланып, иске капка нәумизләнеп, моңланып калган кебек тоелды Сәеткә.

Әнисе чыгып утыра торган эскәмия дә ятим шикелле. Әнисен күтәреп алып киткәндә, малайның эчендә нәрсәдер өзелде. Мәңге әйләнеп кайтмаячак хәзер аның әнисе. Үзенең иң кадерле кешесен югалтты ул.

Малай шул мизгелдә кинәт өлкәнәеп китте. Күз яшен чыгармады.

– Еламыйм, ату әни борчылыр. «Өстән карап тора», – дип әйтте бит Каракай әби.

Көз көне беренче сыйныфка аны бабасы озата барачак. Башта ул малайга фанердан сумка ясады. Аны куе зәңгәргә буяп та куйды. Иске каештан бау да куйгач, җәйли гына сумка, бабасы әйтмешли, букча килеп чыкты. Фатыйма апасы бабасының кәчтүм-чалбарыннан мәктәп формасы текте. Күлмәкне бабасы Теләче базарыннан алып кайтты. Дәфтәрләр, ручка, каләм, кара савыты һәм буяу карандашлары да юнәтте. Сәетнең буяу карандашлары белән тизрәк рәсем ясыйсы килде.

– Бабай, бабай, тизрәк очлап бир инде карандашларны. Мин хәзер сиңа салават күпере ясыйм. Ялантауга кунган айны ясап күрсәтәм. Ул урак хәтле генә булып калгач, шул калкулыкка менеп куна да, тау нәкъ мәчет манарасы була да куя инде, бабай. Төнлә ат саклаганда, үзем күрдем, билләһи дим, очла инде, – дип ялынды ул бабасына.

Ләкин бабасы очламады карандашларны. Мәктәпкә баргачы яңа торсын, диде.

Сәет беренче сентябрьне өзелеп көтте. Вакытны үткәрә алмыйча азапланды.

Ниһаять, беренче сентябрь җитте. Укытучы апалары янында ак алъяпкычлы, көрән күлмәкле кызлар бөтерелә. Нәкъ күбәләкләр инде менә. Чәчләрендә дә – ак күбәләкләр кебек атлас тасма. Малайларның өстендә – өр-яңа кием. Аякларында – ялтырап торган ботинка. Кулларында – сумкалар. Сәет алар янында үзен бик уңайсыз сизде. Кулындагы фанер букчасы да авырайды. Ул аны аркасына яшерде, күзләренә яшь тулып, керфекләрендә эленеп калды. Ярый әле укытучы Нурания апалары, Сәетне кочаклап: «И Сәет, ничек матур киенеп килгәнсең, әнә бабаң нинди матур сумка ясап биргән үзеңә! Мондый матур сумка беркемдә дә юк. Карагыз әле, балалар», – дип, Сәетнең күнелен күтәреп җибәрде. Сәет укытучысының зәп-зәңгәр күзләренә, матур йөзенә карап, яңадан әнисен күргәндәй булды. Аның шушы матур апага барып сыенасы, иркәләнәсе килде, тагын күңеле тулды. Күрше кызы Хәния дә, әтисенең яңа хатынына ияреп килгән Рәфыйк та аның белән бер класста иделәр.

Дәвамы бар >

Рәфикъ ЮНЫС

***

Яшәдек – калмадык төшеп.
Калмадык, югалмадык.
Җилләрдә дә сыгылмадык,
Төртеп тә егылмадык.

Яшь идек без, яшәдек без,
Яндык та көйдек тә без.
Яшьлекнең утлы күмерен
Йөртәбез йөрәктә без.

Тауларына менмәсәк тә,
Үрләренә менәрбез.
Без әле дә кемнәрнеңдер
Төшләренә керәбез!

Үтә гомер, үтә гомер,
Үткән гомер – безнеке .
Үткән гомерләр – безнеке,
Безнең үзебезнеке!

ТӘРТИПКӘ САЛАСЫ БАР

Көтү кайта. Һәр сыерның
Номеры – тамгасы бар...
Әле күпме бу дөньяны
Тәртипкә саласы бар!

Чыпчыкларның, чәүкәләрнең
Сан исәбен алмаган.
Пошилар бар савылмаган,
Тиресе туналмаган.

Турәләргә этләр ырлый.
Мәчеләр никтер мырлый.
Тургай, ни теләсә шуны,
Тота да менеп җырлый.

Кояш әле тәртип белми –
Һәркемгә тигез төшә.
Күпме халык әле һаман
Үз телендә сөйләшә!

БӘХЕТСЕЗЛЕК

Сатучы Р. Га

Торасың син безнең алда,
Әйтерсең лә пьедесталда!
Иң затлы кофта – түшләрдә.
Алтын – кул, муен, тешләрдә!
Елмаясың. Безгә түгел!
Хыялдагы тун, күлмәккә.
Тиеннәр җыя нәниләр
«Песи»гә. Ә син – йөрәккә!
Керем сөенече, чыклап,
Йөрәгеңә иңеп тора.
Кешелегең тамчы-тамчы
Кысырыкланып, кимеп тора.
Менә урын җитмәс булды
Соңгы тамчы җылы канга.
Бары металл салкынлыгы
Синең алсу копилкаңда!
Шыплап тулды! Табышларың
Инде тәңгә йога сыман.
Мимылдаган бу беләктән
Майлы берлек чыгар сыман!..
Бары юан манекен син,
Иңгә ниләр генә салма!
... Арт ишектән сатылмый ул
Бәхет дигән алтын алма!



Язучы сүзе

Календарь

Бу исем начар яңгырамый, шулай бит. Начар булса да бер хәл итеп булмый, мин кушкан нәрсә түгел. Гомумән, кешегә исемне мулла куша. Тәһарәтен алып, бәлешен ашагач, догасын укый да баланың колагына пышылдый. Бәлеш бетә, тәһарәт бозыла, дога онытыла, исем кала. Ризамы бала аның белән, юкмы – гомер буе шул исемне тагып йөрергә тиеш була.

Кешенең кушаматы да була. Кайберсен тегенең артында гына кабатлыйлар, үзенә ишеттермиләр. Мәсәлән, Крокодил. Үзе комсыз һәм бур булса да, башкаларны күз кырыннан чыгармаган бер уртакул түрәне шулай дип йөртәләр иде без бәләкәй чакта. Йөзенә бәреп әйтмиләр инде. Күз алдында: «Әй, Фәлән абзыкай», – дип кенә торалар. Кызык иде ул чакта өлкәннәрне күзәтү. Тегеүрам очында күренүгә үк, нинди дер җирәнү сыман хис белән: «Әнә Крокодил килә инде тагын», – диләр дә, теге килеп җитүгә, елмаеп каршы алалар: «Әй, Фәлән абзыкай, хәлләрегез ничек, фәлән дә төгән...» һәм үтеп китүгә, тагын үзе ишетмәслек итеп кенә «Крокодил» дип калалар. Шулай итеп, теге Фәлән абзыкай үзенең Крокодил икәнен дә белми яшәргә мәҗбүр иде.

Мин моны хәзер генә аңлаган кебек кыланам. Ә бәләкәй чакта алай түгел иде. Әнисе почтада эшләгән дус малай белән без гел гәзит-журнал таратабыз, һәм авылга килгән бердәнбер «Крокодил» журналын гел теге «Фәлән абзыкай»ның капкасына кыстырып китә идек. Һәм аны шушы журналга язылган өчен Крокодил дип атыйлар икән дип уйлый идек. Алай булмаган. Журнал да бөтенләй бүтән кешегә тиешбулган.

Ә кушаматның кайсын йөзенә бәреп әйтәләр. Һәм кеше аңа шулкадәр күнегә, үз исемен әйтеп чакырсаң да, борылып карамый, кушаматын әйтүеңне көтә. Һәм кайчагында үзе дә кушаматын әйтеп таныша. Күрше авылда бер шундый егет бар иде. Үземнекен әйткәч, моның да исемен сорыйм, ә теге: «Майлы авыз». «Кем?» – дип аптырыйм, мондый исемне ишеткән булмагач, ә теге тагын кабатлый: «Майлы авыз инде. Барысы да шулай дип йөртә». Соңрак кушаматының сере дә ачыкланды. Матур итеп, йомшак итеп сөйләшә бу, сөйләгән сүзләре белән бөтен нәрсәне дә майлап-җайлап куя.

Календарь турында яза идем бит әле. Начар малай түгел ул. Эшен дә җиренә җиткереп эшләп куя. Килде-китте сүз дә сөйләп йөрми. Кыскасы, фәрештәнең үзе кебек инде. Аек чагында шулай. Ә айнык чагы юк. Аның иң айнык чагы – махмыр. Айнык чагы булмаган кебек үк, исереп егылган чагы да, чайкалып йөргән чагы да юк. Алай гына да түгел, айнык чагын күргәнең булмаса, син аның исерек икәнен сизмисең. Һәм аның бернича сәер гадәте бар.

Авылдагы бөтен кешенең дә туган көнен белеп тора. Кушаматы да шуннан килә инде. Сабый баладан алып, чал картларга кадәр. Төннең кайсы өлешендә уятып сорасаң да, әйтеп бирәчәк. Һәркемне килеп котлый. Үзе моны болай аңлаткан була:

– Котларга килгәч, тәк тә бер йөз грамм салып бирәләр бит инде.

Янәсе, туган көннәрне белүе бары тик йөз грамм эчү өчен генә. Алай түгелдер инде. Ул бит үзе дә буш кул белән килми. Аннан соң, теге дөньяга китүчеләрнең дә җирләнгән көнен төгәл белә. Календарь инде, кыскасы.

Ә иң сәер гадәте – ураза тота. Йөз граммны каплап куя да биргән закусканы кире кага: «Юк, мин әле уразада». Беренче тапкыр күргән кеше моны шаяру дип кабул итә. Ә ул шаярмый. Ул чынлап та ураза тота. Ашамый, тәмәке тартмый, дога-фәләнен, башка йолаларын өйрәнә... Кыскасы, уразаның бөтен шартын да китерә бу. Бары тик эчүен генә ташламый.

– Мин менә кулымнан килгәннең барысын да эшлим, – ди үзе. – Хәтта махмырдан булсам да, бер тамчы суга үрелмим. Ә эчүне ташлый алмыйм, извини.

– Соң, эчкән килеш... Аны Ходай бары бер кабул итми ич.

– Ул берәү генә, – дип һаман үзенекен сөйли тегеләр. – Бөтен кешене дә кабул итеп бетерә алмаска мөмкин, анысы аңлашыла. Тик бит үз эш аның кабул итүендә түгел.

– Алайса, нидә соң?

– Омтылыш. Омтылыш булырга тиеш.

Һәм текәлеп, барып җиттеме сиңа, дигән кебек итеп карап тора. Календарь! Ә бер карасаң, хаклы бит. Без, адәм балалары, үзебез омтылган ноктага бер кайчан да төп-төгәл барып чыгалмыйбыз инде. Тик аңа карап кына кыйбланы үзгәртмибез, өметне өзмибез. Омтылыш булырга тиеш.

Марат КӘБИРОВ



Рәис Габдулла

21 гыйнвар санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: Мадрид, Полгар, уртак, алыс, өяз, наз, ырмау, Агра, куык, Апе, арту, чапан, чәер, мишень, оча, итәк, Ухта, арфа. **Вертикаль буенча:** нык, чем, Ашот, Аруба, азмы, пыш, Регул, аква, арыну, нансук, дартс, Апач, Ита, көнгерә, Отар, терчә, Азнавур, акка.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Казан һәм Әстерхан ханлыкларының Россия составына керүе ничәнче елларга карый?
А) 1725;
Б) 1552, 1556;
В) 1730.

2 1917–1918 елларда төрки-татарлар парламенты ничек аталган?
А) Милли шура;
Б) Милли конгресс;
В) Милләт Мәҗлесе.

3 Атеизм – ул...
А) Англиядәге җирбиләүче дворяннар;
Б) испан аристократиясе;
В) Алла һәм динне аңлы рәвештә кире кагу.

4 Төньяк сугышы ничәнче елларда була?
А) 1700–1721;
Б) 1653–1655;
В) 1718–1720.

Җаваплар: 1) Б; 2) В; 3) В; 4) А.

ЭШКӘ ЧАКЫРАЛАР

«Талспецстрой» компаниясенә, «Газпромнефть»нең Ямалдагы объектларында вахта ысулы белән эшләү өчен:

МАН 6х6 йөк бушаткычын йөртүчеләр кирәк.

- 60 көн эшләп, 30 көн ял.
- чиста хезмәт хакы аена – **120 мең сум;**
- Нягань шәһәрендәге җыелу пунктына бару-кайту (плацкарт вагонда) бушка;
- туклану, кием-салым бушка;
- медкомиссия узу каралган.

Телефоны: **8(982) 500-00-12**

Реклама

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 18156 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 212

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+